


Мәңгелек рухи байлыкка
Тик илаһи сүз ия.
Хикмәти тормыш булдырган
Аң акылга мәдхия.

Рәис Сафин.

Рәис САФИН




Акылга мәдхия

Казан
2010

УДК 820/89 (470).0
ББК 84 (2 Рос=Тат) -6
С 21

Рәис Сафин
С 21 Акылга мәдхия. (Робагыйлар). - Казан: ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы нәшрият үзәге, 2010. - 216 б.

© Сафин Р., 2010
© Бизәлеше ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы нәшрият үзәге, 2010



Тыйнак яза, җыйнак яза ул

Рәис Сафин исеме укучыларга яхшы таныш дип уйлыйм. Ул - повесть, хикәяләр, шигырьләр, көндәлек матбугатта чыккан күпсанлы публицистик мәкаләләр авторы.

Һәм, ниһаять, менә ул безнең каршыбызда өр-яңа бер сыйфаты белән ачылып китә! Халык авыз иҗатына, робагыйларга тартым дуртьюллыклар язу белән дә чын-чынлап «җенләнә» икән ич ул...

Тормыш-яшәештәге күркәм һәм ямьсез күренешләр, мәхәббәт лабиринтлары, күңел багындагы серләр, яхшылыкны зурлау, дин вә әхлакка чакыру, Аллаһының көченә һәм барлыгына ышану... Комсыз-комагай, байлык колы булма, кешелек сыйфатларыңны югалтма, ялкаулыктан ерак тор... Уян, татар, дөньяда ирек-азатлыктан кадерле нәрсә юк, уянырга һәм көрәшергә вакыт безгә... Җыеп кына әйткәндә, Рәис Сафин үзенең дуртьюллыклары аша

менә шушы хакыйкатьләрне әйтеп бирергә олтыла, алга - яхшылыкка, сафлыкка, әдәп бакчасына өнди.

Бүре ачлыкка түзсә дә,
Коллыкка түзми икән.
Бүредәге бу сыйфатлар
Нигә бездә юк икән?

Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, аның бик күп шигырьләрендә халыкчанлык һәм чичәнлек төсмерләре ярылып ята. Бу инде, димәк, кыскалыкка, сүзләрнең тыгыз һәм җегәрле булуына, шул кыскалык кысаларында фикер бөртекләре дә салынуына олтылыш дигән сүз. Әйтик, мисаллар:

Эшлексез тәхеткә менсә,
Халык икмәксез кала.
Салымнар якадан тотса,
Соңгы чикмәнен сала.

* * *

Акчарлак - Идел өстендә,
Аккош күлләрдә булыр.
Тартар «дөнья тар» дисә дә
Үз куышында торыр.

* * *

Төл үз былбылын сагыныр,
Былбыл гөлгә табыныр.
Бер-беренә багынганнар
Уртак юрган ябыныр. һ.б.

СССР һәм Рәсәй киңлекләрендәге яшәп яткан халык заманында һәм хәзер дә нинди генә социаль тетрәнүләр кичермәгән дә, нинди генә сынау һәм кимсетүләргә дучар буллмаган! Без моны күреп, ишетеп яисә үз җилкәбездә татып та яхшы беләбез. Автор әнә шундый социаль темаларны да үзенең каләм очына «эләктерә»:

Ат янына бозавыңны
Бәйләсәң, табалмассың.
Малыңны дәүләт урласа,
Йөреп тә алалмассың.

Ә нигә, ваучерлар белән алдап, саклык банкларына салган акчаларын сукыр бер тиенгә калдырып, ЖКхХ һәм ипи-сөт бәяләрен көннән-көн күтәрә барып, үз илендәге гражданнарны талауның ачык мисалы шушы түгелмени?

«Базар» димәктән, Р.Сафинның тагын бер шигыренә тукталып китми

мөмкин түгел. Монысы инде Хрущев заманындагы гаҗәеп ахмак-гаделсез хәлләргә шигъри төртмә рәвешендәрәк кабул ителә:

Бозау талап йөргән дәүләт
Илнең каргышын җыяр.
Тар маңгайлы генераллар
Халкының канын кояр.

Соңгы ике юл исә генерал Грачев кебекләрнең 90 нчы еллардагы хәрби кыланышларын, парламентны танклар белән утка тотуларны искә төшерә.

Рәис ага сәяси темаларны да читләтеп үзмый, шигъри укларын көнкадак мәсьәләләргә юнәлтә:

Этләр гомер чиген белә,
Аулакка китеп үлә.
Ил данын саклаган ирләр
Чит җирләрдә күмелә.

Әйе шул, андыйлар арасында татар егетләре дә күп иде, кайсылары Әфганстанда, кайсылары Аффрика илләрендә «интернационалист» дигән исем белән газиз башларын салдылар.

Тауның башын болыт кисә,
Ирләр башын яу кисә.
Рәсәй егетләре яуда
Баш кистерергә ұсә.

Бу юлларны инде турыдан-туры Чечня сугышына бәйле рәвештә аңлавы бер дә кыен түгел. Монысында да инде гапгади татар егетләре яу кырында ятып калды яисә цинк табутларда туган ягына кайтарылды лабаса.

Р.Сафин иҗатында милли шигырьләр дә байтак урын алып тора. Ватанпәрвәр һәм граждании рухлы автор милли темага еш мөрәҗәгать итә, татар халкының язмышы һәм киләчәге хакында гыяки чаң кагарга тели:

Яксаң гына мич җылына,
Җылыны бирә ялкын.
Хәрлек ялкыннары белән
Уятыйк татар халкын!

Яки аның менә болай дип әйтә алган борчулы, фикри юлларын ничек инде хупламыйсың да, ничек инде йөрәгеңә якын аламыйсың ди:

Урыс теле - тир башында,
Башка телләр чүплектә:
Төбәк компоненты дигән
Шовинистик читлектә!

Шөкер, аның фәлсәфи уйланулар белән тукылган шигырьләренә дә юлыгабыз:

Безнең яшәү - күзне ачып йому,
Мәңгелекнең тик бер мизгеле.
Берәү очып, кем мүкәләп бара -
Төрлечәдер гомер тизлеге!

Авторга юмор-сатира хисе дә ят түгел:

Зина кылган хатын-кызның
Таралыр яман аты.
Ир-егетләрне аздыра
Ерылган итәк чаты.

Рәис Сафин төрле сәбәпләр аркасында иҗат эшенә соң тотына, тора-бара «үзем өчен генә язам» дигәннән югарырак күтәрелергә тырыша. Тыйнаклык саклый да белә:

Мин түгел - Тукай, Такташ та,
Шигъри җанлы Гаташ та.
Тик бәхетле булыр идем,
Фикерем калса ташта.


Фикерен ташта һәм укучы күңелендә уелып калсын өчен иҗтиһат, фидакарьлек, үзең генә тапкан шигъри табышлар кирәк. «Эй, әйләнеп тора заманалар, карап-карап тирә-ягына...» Менә шушы юлларны автор заманчалык рухы белән тагын да көчәйтеп җибәрә:

Урак-чүкеч өсләрендә әнә
Ике башлы козгын кагына!

Рәис абыйга әнә шундый шигырьләрне күбрәк иҗат итүен телибез. Бер татар шагыйре әйтмешли, «Хәйам белән чәкешерлек» фикерләр тудыру фарыз.

Рашат Низами.
Ноябрь, 2009.

Мәңгелек рухи байлыкка
Тик илаһи сүз ия.
Хикмәти тормыш булдырган
Аң-акылга мәдхия!



* * *

Тегеңә дә борчак атты,
Моңа да борчак атты.
Борчаклары, ядрә булып,
Кире үзенә кайтты!

* * *

Бүре ачлыкка түзсә дә,
Коллыкка түзми икән.
Бүредәге бу сыйфатлар
Нигә бездә юк икән?!

* * *

Нигә татар үз-үзенә
Бүредәй тугры түгел?
Тугры булса, бәйсезлекне
Кайтарыр иде җиңел!

* * *

Аттан ала-кола туа,
Бу табигый төс була.
Актан кара, карадан ак
Туганы үксез кала.

* * *

Кәкре каенга кар йокмас,
Зиректән дуга чыкмас.
«Мин!» - дип масайган дуганы
Тәртәләр өстә тотмас.

* * *

Арыслан таба икене,
Дуңгызлар - уникене.
Арыслан - җәнлекләр шаһы,
Ә дуңгыз ит бүкәне.

* * *

Чыбыктан себерке булган,
Үзен зурдан зур күйган.
Чыбыкмы ул, себеркеме, -
Булсын себерә торган.

* * *

Нәни чишмә ташны тишә,
Юкә чәй имән яра.
И кеше, булма бичара,
Бичарага ни - чара?

* * *

Тирәгең булса терәгең,
Булыр һәрчак кирәгең.
Тирәксез, терәксез калсаң,
Кемгә булыр кирәгең?!

* * *

Эт өере өреп бара
Бүре өстенә таба.
Шыңшып яткан ялгызак эт
Итәк астыннан каба.

* * *

Әкияти мич өстендә
Хөрәсән кайтып килә.
Кырын ятып әвен суккан
Кешедән шайтан көлә.

* * *

Койрыгын чәнчеп чапканны
Куып та җиталмассың.
Ике куян куып йөрсәң,
Бәрсен дә тоталмассың.

* * *

Эт котырса, теш ыржайтып,
Хуҗасын килеп тешли.
Илне талап җыйган байлык
Кешедән ерткыч эшли.

* * *

Калҗа өчен эт талаша,
Калҗа беткәч ялаша.
Ә кешеләр эттән узып,
Сөяк өчен талаша.

* * *

Эте-бете этлек кыла,
Чабуны ерта арттан.
Илдә атыш барган чакта
Исән калырмы Ватан?

* * *

Олы «дәдәй» бик ярата, -
Этне эттән талата.
Икәүгә сөяк ата да,
Кырын карап тик ята.

* * *

Сокланалар җырлавына,
Булса да ул яшь кенә.
Сандугач та бик кечкенә,
Эче тулы төш кенә.

* * *

Игелекле, затлы булу,
Ата-бабадан килә.
Бүгенге көннең байлары
Затлы кешедән көлә.

* * *

Дөньяның бажалары күп,
Кодалары ләкин аз.
Бажалар күсәк тоткандa
Ерак йөрмәс инкыйраз.

* * *

Эшлексез тәхеткә менсә,
Халык икмәксез кала.
Салымнар якадан тотса,
Соңгы чикмәнен сала.

* * *

Юньсез юньгә керер димә,
Денсез денгә керсә дә,
Юньсезнең уйлаган уе
Гәм коралы... кесәдә.

* * *

Гәр күжәйдән чебеш чыкмый,
Чыкканын хуҗа тотмый.
Халык ил хуҗаларына,
Чебеш бәясе тормый.

* * *

Читлеккә күнеккән кошның
Иректә башы әйләнә.
Мөстәкыйльлек дигән сүзгә
Манкорт татар бәйләнә.

* * *

Кар-яңгыр явып яр тулмас,
Яумаса ташу буллмас.
Ишелгән яр талларына
Асыл кош килеп кунмас.

* * *

Акчарлак - Идел өстендә,
Аккош күлләрдә булыр.
Тартар «дөнья тар» дисә дә,
Үз куышында торыр.

* * *

Былбылны, читлектә тотып,
Сайрарга өйрәтмиләр.
Иректә сайраган кошлар
Җырлы-моңлы, дәртлеләр.

* * *

Бүренең азыгы һәрчак
Сизгер борны очында.
Кешенең бәхете исә
Тырыш куллар учында.

* * *

Күләгә булган урында
Җиләк кызарып пешми.
Шайтан таягы янында
Асыл гөлләр дә үсми.

* * *

Чөйне чөй кагып чыгара,
Киңәя бара ярык.
Чөй кага белмәгәннәрдән
Замана инде гарык.

* * *

Эт иснәгән судан арыслан эчми.
Без Иделнең суын эчәбез.
Этләр белән бер табактан ашап,
Этләрдән дә түбән төшәбез.

* * *

Коррупция кочып алды,
Юктыр котылыр әмәл.
Котсыз ришвәтчелек булып,
Ил-җиргә килде әҗәл.

* * *

Эшсез кешеләр эт җыяр,
Хөрәсәннәр бет җыяр.
Беткә баткан бомж халкын
Эшсез ил кая куяр?

* * *

Әнендә өреп ятудан
Сак этләре дә туя.
Әендә эшсез яткан ир
Кадер-хөрмәтен җуя.

* * *

Туфракта аунаган этнең
Өсте тулы тузан, кер.
Этнең күңеле - бер сөяк,
Мәченең күңеле - сер.

* * *

Эт белән мәче дус буллмас,
Булса да бергә тормас.
Үзен хөрмәт иткән затлар
Ят белән оя кормас.

* * *

Зәмзәһир салкыннарда эт
Оясында сызланыр.
Мәче, аяк арасында
Куштанланып, сырланыр.

* * *

Уртак малны этләр сөймеи,
Бер табактан аш җыймый.
Урысны татар сыйдыра,
Татар урыска сыймый.

* * *

Этең янәшәңдә булсын,
Буре белән дау корсаң.
Этең калдырма үзеңнән,
Буреләргә ау барсаң.

* * *

Гәркемнең дә үз эше бар,
Эше барның ашы бар.
Берәүнең кулында көрәк,
Бишәүнең кашыгы бар.

* * *

Ач эт салкыннан бөрешеп,
Оясында тик ятар.
Ялкау хуҗаның сарыгын
Буре сыртына атар.

* * *

Эт өер булып йөрсә дә,
Сөяк өчен талашыр.
Кайсы - калҗага алданып,
Бүре белән ярашыр.

* * *

Бүре баласы эт буллмас,
Берәүгә дә баш бирмәс.
Һәркемгә дә койрык болгап,
Арттан ияреп йөрмәс.

* * *

Эт эчәгесе, дигәннең
Ни башы, ни очы юк.
Кеше буллмаган кешенең
Кеше белән эше юк.

* * *

Бала кошның авызы зур,
Кешенең нәфесе зур.
Икесе дә авыз ачып,
Ашарга сорап торыр.

* * *

Дәртле булган айгыр кешнәр,
Ач сөлек ачы тешләр.
Икесенең дә хәҗәте -
Җан иясенә ишләр.

* * *

Гөл үз былбылын сагыныр,
Былбыл гөлгә табыныр.
Бер-беренә багынганнар
Уртак юрган ябыныр.

* * *

Акыллы кеше балтасын
Һич алышмас шөшлегә.
Эч серләрен дә сөйләмәс
Бытбылдык күк кешегә.

* * *

Кешене һәлакәт сыный,
Кош һавада сынала.
Әнисенең сулышыннан
Тынсызлар да тын ала.

* * *

Төнлә кычкырган әтәчнең
Иртән башын кисәләр.
Теле озын кешеләрнең
Гомерен тиз өзәләр.

* * *

Эше юкның көн дә бәйрәм,
Бәйрәмдә калдык хәйран.
Еллар буе эшләмичә,
Йөрибез булып вәйран.

* * *

Изге эшнең иртәсе юк,
Күңелнең киртәсе юк.
Изге күңелле кешедә
Изгелекнең чиге юк.

* * *

Ата-анасының йөзе
Баласында сын ала.
Остазының дәрәҗәсе
Шәкертендә сынала.

* * *

Вакыт һәрчак хәрәкәттә:
Кем таба, кемдер җуя.
Берәүләргә төн батканда,
Ярканат табын җыя.

* * *

Кырык биш ел аяк табаннарын
Завод юлын таптап талдырды.
Тик икмәген дәүләт талап алды,
Ачтан үләр көнгә калдырды.

* * *

Һәфесе алдан йөргәннең
Җанына шайтан хуҗа.
Шайтан коткысында булсаң,
Тормышың синең нужа.

* * *

Берәүгә баллы да ачы,
Тук тычканга он төче.
Яшәүнең төмен үзгәртә
Кадерен белгән кеше.

* * *

Мәчесе юк тычкан асрар,
Үзенә зыян ясар.
Тычкан тотмаган мәчеләр
Тычканнардан да начар.

* * *

Бичәсенә тугры бүре
Ана эткә иярмәс.
Тән сатып кәсеп иткәннәр
Хәшәрәттән җирәнмәс.

* * *

Уйламый башлаган эшнең
Башы-ахыры буллмас.
Очлары ялганмаган эш
Бер тиенгә дә тормас.

* * *

Яксаң гына мич җылына,
Җылыны бирә ялкын.
Хөрлек ялкыннары белән
Уятыйк татар халкын!

* * *

Оясын эт тузгытканнан
Эрләп оясыз тормый.
Тик ул инде этләр йөргән
Урында оя кормый.

* * *

Ут яксаң төтен чыкмый,
Төтен - тормыш өлгесе.
Теле нинди - милләт шундый,
Тел рухият көзгесе.

* * *

Башы буллмаган эшләрнең
Аяк-кулы бәйләүле.
Баш белән башланган эш тә
Аяк-кулларга бәйле.

* * *

Тир түгеп гомер иткәннәр
Барның кадерен белә.
Ялкау - булганын да җуя,
Эт типкесендә үлә.

* * *

«Ярар»ның башы авыртмый,
Эше ярты булучан.
Теле тегермән тартканга
Кул кушырып торучан.

* * *

Арыслан ачта - төлке тук,
Тукның ачта гаме юк.
«Төлкеләр» басты дөньяны,
Азгынлыкның чиге юк.

* * *

Телдән килгән, кулдан килми,
Тел җиткәнгә, кул җитмәс.
Тырыш кешедән тир кипми,
Ялкаулардан чир китмәс.

* * *

Урамда җил куып йөргән
Исәрнең исәре юк.
Җилсез тегермән әйләнми,
Ташының күләре юк.

* * *

Эш ашата, эш өйрәтә,
Ул ата-анаң кебек.
«Эш урманга качмас» дисәң,
Игелек көтмә берүк.

* * *

Теленә шайтан төкергән,
Бар сүзе үен-көлке.
Теле белән урак ура,
Йорттта идәне чүпле.

* * *

Әбиләр чуагында да
Эзләгән корт бал табар.
Алтмыш-җитмеш яшендә дә
Ир-егетләр мал табар.

* * *

Авыр тормыш тилмертә,
Җиңел тормыш тилертә.
Авыры да, җиңеле дә
Үрле-кырлы сикертә.

* * *

Шылтырый да, кайчак, савыт-саба
Бәгырьләрдә кала чир-яра.
Чир-яралар кайтавазы булып,
Йөрәк сыкрап ала бер ара.

* * *

Көче барлар берне егар,
Гыйлемле меңне егар.
Кылны да кырыкка ярыр,
Ташларның маен сыгар.

* * *

Май чүлмәге, чүп чүлмәге
Тышларыннан билгеле.
Төс-кыяфәттән күренә
Кешеләрнең кеммеге.

* * *

Бәллүр бокалларның чыңы
Йөрәкләрне җилкетә.
Аллы-гөлле балкышлары
Мескеннәрне өркетә.

* * *

Чөйне чөй бәреп чыгара,
Кирәкмәстән чөй какма.
Чөй кагучы бәндәләрдән
Денең, иманың сакла!

* * *

Яңалык - кызлыклы кыз ул,
Ә искелек - тол хатын.
Гүр ялтыраган нәрсәкәйләр
Түгел асылташ, алтын.

* * *

Ярымшәрә йөргәннәрнең
Тышкы ягы гөл кебек.
Тик мең төрле сырхаулардан
Уты сүнгән көл кебек.

* * *

Яхшының яманы да бар,
Син аны ашка чакыр.
Аш атканга ул таш атса,
Ташы үзенә кайтыр.

* * *

Байлык туплау, тәмле ашау, -
Шуллы кеше бәхете?
Хайваннар да ашый-эчә, -
Бездә акыл рәхәте.

* * *

Хәләл, хәрәм - икесе дә
Байлык табу юллары.
Күпне кочып, азны учлап
Кала нәфес коллары.

* * *

Фани дөнья - чишмә башы,
Мәңгелеге - ахирәт.
Ике дөньяда яшәүдә,
Чишмәң саф булу кирәк.

* * *

Хак Тәгалә Җир-Күк, Галәмнәрне,
Тереклекне юктан бар итә.
Кешеләрнең көче бар булганны
Барлау өчен генә тик җитә.

* * *

Кемне җитез аяклары,
Кемне акыл ашата.
Акыллылар читкә качты,
Ил күтәрәмдә ята.

* * *

Табигатьнең тиңсез дүрт фасылы
Бер-бер артлы йөри бәйләнеп.
Үзен хөрмәт иткән җан иясе
Асылына кайта әйләнеп.

* * *

Югарыга менү - мораль,
Аста торуы - оят.
Менү өчен кирәк ният,
Юлы аның - хөррият.

* * *

Утырып утын кискәнгә
Шайтан сыбызгы биргән.
Үзең ише ялкау белән
Кәлимә ясап йөр, дигән.

* * *

Тырмаша, мәш килә халык,
Кем талый, кемдер алдый.
Илнең кыяфәте нинди,
Без - күләгәсе шундый.

* * *

Карның башын җилләр ашый,
Татар башын кем ашый?
Кем милләткә яла ягып,
Татардан дошман ясый?!

* * *

Үз телен, моңын, хак динен
Белми манкорт балалар.
Катнаш гаилә балалары
Мәнсез булып калалар.

* * *

Итәкләр тиң - җиңе белән,
Ә кеше ише белән.
Борынгылар җиде буын
Нәсел-нәсәбен белгән.

* * *

Ерткычлар өере этнең
Сөяген тартып алды.
Илнең хөрмәтле затлары
Эт халәтендә калды.

* * *

Аю җиңә көч белән,
Кеше - акылы белән.
Аларга шулай булырга
Аллаһтан әмер иңгән.

* * *

Ни чәчсәң - шуны урасың,
Тугайларда тал үсәр.
Әтисе мал талаганның
Балалары - башкисәр.

* * *

Балта тота белмәгәннәр
Бүрәнәгә үпкәләр.
Кемгә үпкәләр меңләгән
Йортсыз-нисез ятимнәр?

* * *

Булмастайлар сәбәп табар,
Балтага гаеп тагар.
Эштә шүредәй булганнар
Ашын бүредәй кабар.

* * *

Әдәп-әхлак мода түгел,
Тыңламыйлар бу хакта.
«Җилдән туган» балаларның
Уннан сигезе хаста.

* * *

Энҗе-мәрҗән, асылташлар
Чит дәүләтләргә ага.
Ил хуҗалары аларны
Этләр муенына тага.

* * *

Иң игелекле дәһилек -
Кешегә бәхет бирү.
Иң зур бәхет үз-үзеңне
Бәхетле итә белү.

* * *

Күңел бакчаңа кем кермәс
Капкасы ачык булса.
Кеше сүзе, вәсвәсәләр
Урап алыр, буш торса.

* * *

Вакытны үзучылар бар,
Язмышны юктыр узган.
Әле атмаган куянга
Ашыгып асма казан.

* * *

Көндез чәлсәң, кеше күрә,
Төнлә йөрсәң, эт өрә.
Гомер буе урлап, талап,
Рәсәй халкы көн күрә.

* * *

Җил исми яфрак селкенми,
Төтенсез булмый ялкын.
Язын җиргә орлык чәчсәң,
Көзен җыярсың алтын.

* * *

Гөрләвекле язлар җитте,
Хатын-кызга хут керде.
Кендек ачып йөргәннәрнең
Артларына ут керде.

* * *

Быел кыш кышлыгын итте,
Җәй җәйлеген итәрме?
Барыс елында иген үсәр,
Эт елында үсәрме?

* * *

Табигать ул - серле хикмәт,
Кышын кар - көзен икмәк.
Май аенда кырау төшсә,
Көз иген булыр имгәк.

* * *

Заманга килсә ахыр,
Юллары буллас такыр.
Заманаңың тегермәне
Таш түгел, башны тартыр.

* * *

Һәр тауның да үз кыясы була,
Батар көннең атар таңы бар.
Йөрәкләрдә чакма чагылганда
Җан чыкмаган төндә өмет бар.

* * *

Шомарса да, бакыр алтын буллас,
Бакыр белән казан ямыйлар.
Энҗе-мәрҗән, асылташлар, әнә,
Калфакларда ничек балкыйлар!

* * *

Кем алдый бүген, кем талый,
Заманына күрә әмәле.
Бәддогалы хәрәм малларының
Игелеген күргән юк әле.

* * *

Тауның башын болыт кисә,
Ирләр башын яу кисә.
Рәсәй егетләре яуда
Баш кистерергә үсә.

* * *

Давыл буллмый, явым буллмый,
Яңгыр явып яр тулмый.
Гәр яуган кар ак булса да,
Гәр ак әйбер кар буллмый.

* * *

Җәйләр җитсә яшен яшьни -
Бал кортлары бал ташый.
Җәен печән әзерләгән
Кышын ат ите ашый.

* * *

Яхшы сүз ул - җан азыгы,
Яман сүз булыр азау.
Биш сыерны йолкып имәр
Авызы йомшак бозау.

* * *

Тауга карап тау буллмассың,
Тау кыялары текә.
Ямьле үзәннәрен иңләп
Йөрүләргә ни җитә?!

* * *

Хәсрәт хәсрәткә охшамас,
Хәсрәт урыны бушамас.
Хәсрәт күрмәгән ир-егет
Ил агасы булаллмас.

* * *

Караңгының күзе юк,
Телсезләрнең сүзе юк.
Телсез, сүзсез заманада
Сарык исән, бүре тук.

* * *

Сәламәтлек - байлык, диләр,
Байлыкны таба вакыт.
Шул сәламәтлек, байлыкка
Буллмый вакытны табып.

* * *

Сай елга чылтырап агар,
Тирәне саллмак агар.
Алга ашкынган дулкыннар
Дәрья-диңгезне табар.

* * *

Кыланышы кырга сыймый,
Белгәннәр хәйран кала.
Заманның әрсез ишәге
Аттан узмакчы була.

* * *

Сукбай күргәнне эт күрмәс,
Җәйгә чыккан җан үлмәс.
Башында акыл булганнар
Эт типкесендә йөрмәс.

* * *

Үзе егылган еламый,
Елак тормыш кораллый.
Аяк чалып егылганнар
Инде басып тораллый.

* * *

Тауның күрке булса болак,
Күл буе күрке - куак.
Кеше күрке кием-салым,
Тик алар булсын тыйнак.

* * *

Су башы булса болакта,
Очы күлдә буллакта.
Татарның да яшәеше, -
Ислам дине тотмакта.

* * *

Торгын суны үлән баса,
Үләнгә сусар кача.
Куркып, посып ятма, татар,
Азатлык күзен ача.

* * *

Булдыксызга балта бирсәң,
Таш ярам дип, баш ярыр.
Егам дигән агачын да
Үз өстенә аударыр.

* * *

Йолшак агачны корт баса,
Яткан ташны мүк баса.
Аяныч хәлләрдә калдык,
Шанлы идек ләбаса.

* * *

Ялгыз агач - җил-давылдан,
Урман курка балтадан.
Сапсыз балта - җансыз ята,
Хуҗа ничек мал табар?

* * *

Җил чәчсәң - давыл урырсың,
Өермәсен күрерсең.
Давыл, өермә эчендә
Кан-яшь түгеп йөрерсең.

* * *

Хәтәр егетләр хәтәрдән
Башына ядрә ала.
Талап җыйган хәрам малы
Җиде ятларга кала.

* * *

Чәй чәйне бәреп чыгара,
Алмаз алмазны кисә.
Алмаз тоткан башкисәрләр
Рәсәй илендә цсә.

* * *

Тиен цз куышын табар,
Сулар диңгезгә агар.
Татар, син дә тап ишеңне!
Ишегең ятлар кагар.

* * *

Каен - тузы белән күркәм,
Имән - ныклыгы белән.
Кызлар каенга тиң булса,
Ир-егет булыр имән.

* * *

Болыттан качып йөгерсәң,
Юлыгырсың явымга.
Барына риза буллмасаң,
Малың очар давылга.

* * *

Байталлардан алмачуар,
Ала-кола да туар.
Эттән бүре тумаса да,
Кешедән «бүре» туар.

* * *

Каен төбенә кар ятмый,
Аны тамыры саклый.
Татарның да тамыры нык,
Аны иманы саклый.

* * *

Анасыз корт күп булмас,
Бал җыйса да, им булмас.
Татар - котсыз гадәтләрдән
Арынмаса, ил булмас.

* * *

Корт анасын тоткан гаярь
Бөтен күченә ия.
Хәр дәцләтне тотар өчен
Кирәк милли идея.

* * *

Корт анасы - йорт анасы,
Ояга алдан керә.
Хатын-кызның да кадере -
Ана булганга күрә.

* * *

Корт анасы - йорт анасы,
Үзенең күчен барлый.
Кыр-далага, болыннарга
Илче-кортларын юллый.

* * *

Ач сөлекләр ачы тешли,
Тик яхшы канны эчми.
Илнең сөлек-түрәләре,
Халык тәненнән төшми.

* * *

Буа булса, балык булыр,
Балык булмас коеда.
Иләс булмаганны эзләп,
Йөри гомер буе да.

* * *

Гәркемнең үз мөхите бар:
Берәү суда, корыда.
Таракан ярыкка посып,
Яши казан кырында.

* * *

Алабуганың - колагы,
Камбаланың күзе юк.
Күзсез, колаксыз тирәнең
Бер акыллы сүзе юк.

* * *

Роза - гөлләр алиһәсе,
Тик чәнечкесе тырный.
Роза гөлен яратканнар
Чәнечкеле дип тормый.

* * *

Юкәнең чәчәге дә бал,
Черегe булыр дару.
Хуш исле себеркесе дә
Тәннәрне итә ару.

* * *

Ачның ашы - алабута,
Тук кеше йолкып ата.
Илне иңендә күтәргән
Буын кораксып ята.

* * *

Камыш суда утырса да,
Үләннән элек корый.
Гомернең дә озынлыгы
Чәсел-нәсәпкә карый.

* * *

Болыт ала-кола булса,
Яңгыры усал чала.
Яшерен сереңне белгән
Дусларың зәһәр чага.

* * *

Чебен дулап тәрәз ватмый,
Сулар да кире акмый.
Ач бүредәй уласаң да
Кичәге көнең кайтмый.

* * *

Талны очыннан бөгәләр
Сыек чыбык чагында.
Милли тәрбияне башла
Карыныңда чагында.

* * *

Уңган кеше ут уйната,
Куллары эшкә ята.
Ул хәтта кар өстендә дә
Учакта су кайната.

* * *

Камышларның кайбереннән
Кешеләр шикәр сыга.
Буй-буй үскән камышлардан
Берәүләр чыпта суга.

* * *

Бер тарыдан ботка буллмый,
Бер агач мичтә янмый.
Бер милләт тә үзе генә
Ил-җирдә яши аллмый.

* * *

Коры агачлар янында
Чи агачлар да яна.
Яшь урманнарны екканда
Белегез соң чик-чама!

* * *

Сырланнар сырып алырлар,
Бөрлән бөтереп алыр.
Ат аунаганнан төк кала,
Бездән дә бер эз калыр.

* * *

Көзен шайтан таягы да
Салкыннарга бирешә.
Каен тузы да кояштан,
Җил-яңгырдан бөрешә.

* * *

Урманда йөреп тапмаган
Саплык агач кисәге.
Көн үтсенгә яшәүченең
Тормышы да - кичәге.

* * *

Талга сөялгән талчыкмый,
Кирше-кершене яклый.
Акыллы кеше киршегә,
Ихтирам хисе саклый.

* * *

Эзләгән корбанын таба,
Корган капкын буш тормый.
Үрмәкүч пәрәвәзендә
Әнә, чебен кыштырдый.

* * *

Бар бәрәкәт - хәрәкәттә,
Болыт чыкмый, җил исми.
Тәгәрәтсәң, ташларның да
Өстенә үлән үсми.

* * *

Йомычкалар оча башлый
Күршең әгәр утын ярса.
Күләгәсе сиңа төшә
Балаң тайгак юлдан барса.

* * *

Яшен яшьнәп, күкрәп яуган
Эре яңгыр тиз туктар.
Вак яңгыр кебек вакчылдан
Йөрәгең әрнеп сыктар.

* * *

Сарыктан берничә бәти,
Аттан бер колын туа.
Ат - сабантуйлары күрке,
Тәкәдән шашлык була.

* * *

Байтал чабып бәйге аллмас,
Яныннан тае каллмас.
Ябаганы мактап кына
Канатлы тулпар буллмас.

* * *

Чабыш аты тай чагыннан
Тыпырдап биеп тора.
Булырдай кеше булдыра -
Комнан шәһәрләр кора.

* * *

Ак тамырны ат ярата,
Ак тамыр тынгы бирми.
Әгәр бия кешнәмәсә,
Янына айгыр килми.

* * *

Айгырга атланып йөрсәң,
Ил агасы булырсың.
Тайны иярли алмасаң,
Булыр көлке, булыр соң.

* * *

Байталларның хакы олы,
Айгырның даны олы.
Ата-ана йөз аклыгы -
Тәүфыйклы кызы, улы.

* * *

Үлемне мәгъкүль күрә зат
Буй сындырып торганчы.
Алты көн айгыр булу шәп,
Алтмыш көн ат булганчы.

* * *

Мең чакырым юл-суклаклар
Бер адымнан башлана.
Бисмиллалы эш-гамәлләр
Аллаһка багышлана.

* * *

Күл тирәсе саз булса да,
Күңелеңдә яз булсын.
Аллаһ ризалыгы өчен
Кешеләр гамәл кылсын.

* * *

Утның көчен казан белә,
Диннең көчен адәм белә.
Илаһи тиңсез көч-кадрәт
Тик Аллаһыдан килә.

* * *

Хакыйкатьне белим дисәң,
Коръән-Кәримне өйрән.
Яшәешнең кануннарын
Аллаһ Коръәндә биргән.

* * *

Явызлык көчле булса да,
Яхшылыкны җиңаллый.
Берни хәрәкәткә килми -
Аллаһтан фәрман булмый.

* * *

Карышып үскән агачны
Туры итә алмассың.
Кире беткән кеше белән
Юл йөрергә язмасын.

* * *

Сандугач белән таң туа,
Карлыгач көн китерә.
Дин белән рухи нур тула,
Фән тормышка ямь бирә.

* * *

Урман башын кемнәр тарый?
Усак җилсез калтырый.
Үзенә кирәк чагында
Төкселәр дә ялтырый.

* * *

Мәчеләрнең тычканнарны
Кызганулары ялган.
Көчсез көчленең корбаны, -
Дөнья шулай яралган.

* * *

Үлемнең күзенә карап,
Кыл өстендә торсаң да...
Шайтаннан ярдәм сорама,
Күпме мохтаҗ булсаң да.

* * *

Белемеңне уртаклашсаң,
Тоташа ике күңел.
Белем биргәннән бөлмисең,
Белем ул - акча түгел.

* * *

Черек агачны корт баса,
Каерылганны - буран.
Каерылган, черегәннәр
Булалар һәрчак корбан.

* * *

Тормыш һәрчак безне сыный,
Йә сөеп ул, йә тырнап.
Бәлагә тарысаң - сабыр,
Баеп китсәң - бул тыйнак.

* * *

Абаганың ут чәчәге
Атып җитми юк була.
Мәңге үкенечтә кала
Чәчәк атмаган бала.

* * *

Ялган - аякларсыз калса,
Канатларында оча.
Йә кайгы булып урала,
Йә сагыш булып коча.

* * *

Болак башы - торак башы,
Торак башта аш пешә.
Булыр-буллмас патшалар бит
Ил тәхетеннән төшә.

* * *

Җил чәчкәннәр җил урырлар,
Давыл чәчкән давылны.
Чакматаштан чыккан ут та
Ялмап чыгар авылны.

* * *

Таулардан ургып аккан су
Кыя-ташларны кисә.
Берәү инеш кичә аллый,
Берәү дәрьялар кичә.

* * *

Алмагачның алмалары
Үзеннән ерак төшми.
Кычытканның сабагында
Мәк чәчәкләре үсми.

* * *

Милли ашларны пешермә
Кукуруз камырыннан.
Газиз халкым, аерылма
Борынгы тамырыңнан.

* * *

Аерылган аю ашы,
Бүленгән бүре ашы.
Илен сатып, динен сатып,
Киселә татар башы.

* * *

Күбәләкләр корбан була,
Ялкын очында очып.
Төнге «күбәләкләр» ята
Әҗәл чирләре кочып.

* * *

Кылыч таккан хәтәр түгел,
Хәтәр лыгырдык кеше.
Телен тыя белмәгәннәр
Була бытбылдык ише.

* * *

Арканга бәйләнгән атлар
Казыгына урала.
Арканын өзгәннәр генә
Азатлыкка юл ала.

* * *

Җилбәзәкләр, җилкуарлар
Алдагысын уйламый.
Акбүз атлар, асыл затлар,
Мәйданнарда уйнамый.

* * *

Гәрнәрсәнең үз бәясе,
Гәркемнең бар үз хакы.
Тиҗәләрнең золымыннан
Зар елый илнең халкы.

* * *

Гәр очкан кош лачын буллмый
Кыя башына кунмый.
Теләмәгән агачына
Кошлар да оя кормый.

* * *

Кош очса, кәрван юл ала,
Таш астыннан су ага.
Асыл ташлар җирдә ятмас,
Асыл ташка ил бага.

* * *

Ихлас кеше - туры кеше,
Юхаланганы хәтәр.
Еланның да тышы йомшак,
Ә эче тулы зәһәр.

* * *

Чакканы, чакмаганы да
Елан диеп атала.
Яхшысы да, яманы да
Милләт йөзендә кала.

* * *

Әй, татар, гамьсез җаннарны,
Йоклаганнарны уят.
Җил-давыл купкан күңелдә
Утлы ялкыннар уйнат.

* * *

Гәркем үз белгәнен эшли,
Үз хаҗәтен булдыра.
Елан - агуны, бал корты балны
Бер чәчкәдән суыра.

* * *

Калку урынга кар ятмый,
Кояш чыкмый - таң атмый.
Табигатьнең үз законы -
Ахшамсыз кояш батмый.

* * *

Язгы кычыткан им булыр,
Яшел чирәм чир куар.
Җиргә ятып аунаган ат
Җирнең сихәтен тояр.

* * *

Бүренең табаны талган,
Кыр-далада ач калган.
Җәнлек-җанварлар азыгын
Аюлар талап алган.

* * *

Азган-тузган азгыннарның
Баш очларында казык.
Уйнаклап сикергән чабак
Чуртанга була азык.

* * *

Ләм, үлән араларына
Балык уылдык чәчә.
Җәтмә сала, тыелганын
Белсә дә кеше гәрчә.

* * *

Җай белмәсәң, җим элмәсәң,
Балык капмый кармакка.
Майсыз ботка авыз ерта,
Тәме йокмый тамакка.

* * *

Гәр кешегә күңел ятмый,
Гәр күлдә аккош буллмый.
Аккошлар йөзгән күңелгә
Хыянәт килеп кунмый.

* * *

Күзләрен кан баскан тиран
Илләрне итә тар-мар.
Оны, йоны да буллмаган
Бер тартарга дөнья тар.

* * *

Җемелдек таң йолдызының
Балкышы сүнә иртән.
Күлләрдә чуртан булганчы,
Күктә чулпан бул икән.

* * *

Кош сайравыннан билгеле,
Гәр кошның бар үз моңы.
Гәр халыкның да моңы бар,
Моңында - аның җаны.

* * *

Курыккан куактан өркер,
Көндез дә посып йөрер.
Яхшылык эшләүчене дә
Дошманы итеп күрер.

* * *

Аның кемлеген сорама,
Җавапны бирер теле.
Теле әйткән бер сүзеннән
Ачыкланыр кемлеге.

* * *

Еланның аяклары юк,
Ләкин һәр җирдә йөрер.
Елан телле кешеләрнең
Зәһәре җанга керер.

* * *

Ат барыр юлын югалтмый,
Ул җирне тоеп атлый.
Җирне тоймаган кешеләр
Тормышта юлын тапмый.

* * *

Печелгәннәр затлы нәсел түгел,
Алашаны атка санама.
Ил, халыкны яңа байлар печте,
Алашалар - кая карама.

* * *

Кара йөзләр пычракларын
Пакъ йөзлеләргә ата.
Бытбылдыклар зур мөнбәрдән
Сүз боткасы болгата.

* * *

Чыпчык учларга утырмый,
Утырса да, тик тормый.
Дөнья күргән карт чыпчыкны
Кибәккә алдап булмый.

* * *

Карлыгач - өй кыегына,
Сандугач талга куна.
Кошлар да күкәй салалар
Оясы булгач кына.

* * *

Бер сандугач яз китерми,
Яз килми - җир өлгерми.
Лаеш шулпасы эчмичә
Кешегә акыл керми.

* * *

Гавада очкан торнага
Учта барга алышма.
Очканнар белән ярышма,
Җәяүледән калышма.

* * *

Мөселман догасыз йөрми,
Ат та дагасыз буллый.
Догасыз, дагасыз җаннар
Ераккa бара аллый.

* * *

Бакалар туе баткаклык,
Катнаш никах - ахмаклык.
Баткаклыктагы татарга
Чәселсез дә каллаклык.

* * *

Иясез җылы урынга
Еланнар ияләшә.
Милли хисләрең янында
Халкың булсын янәшә.

* * *

Милләтләрне чәкештерү -
Руста дәүләти йола.
Ике күгәрчен талашса,
«Дәдәй»гә йоны була.

* * *

Арба өстендә каргалар,
Чукый бара ярмалар.
Каргалар чукып канаткан
Төзәлерме яралар?

* * *

Акча колына әйләнсә,
Кешедән намус кача.
Сандугачлар сакауланса,
Урманны карга баса.

* * *

Үләксә исең сизенсә,
Карга өере тузгый.
Ил өстендә кара болыт
Биш гасыр инде үзмый.

* * *

Урманның бер почмагында
Тол кәкүк аваз сала.
Чит ояга күкәй салган
Мәхлүкләр ялгыз кала.

* * *

Тай азгыны атка иярер,
Ат азгыны тай була.
Төртәгә типкән азгынны
Хуҗа итлеккә чала.

* * *

Мактанса да ишәк - тулпар,
Ә карга шоңкар буллмый.
Эшкә ашмаган гамәлләр
Сукыр тиен дә тормый.

* * *

«Сөембикә», «Айсылу»лар
Үтәли тишеп үтә.
«Тәвәккәл таш ярыр», - диеп,
Халык бик дөрес әйтә.

* * *

Ялкау һәрчак сәбәп таба,
Калган эшкә кар ява.
Булдыклы - комнан бау ишә,
Учы белән таш яра.

* * *

Байгышлар, байлар талашка-
Заманнар үтте-китте.
Хәзер олигархлар талый...
Ил-җирне байгыш итте.

* * *

Кул-кулны юа, ике кул
Битнең карасын юа.
Кара йөз юылган саен
Аклык-сафлыгын җуя.

* * *

Карга халкы бер-берсенең
Күзен чукып үк аллый.
Каргалар, кешеләр түгел
Кардәшенә зар саллый.

* * *

Ат янына бозавыңны
Бәйләсәң, табалмассың.
Малыңны дәүләт урласа,
Йөреп тә алалмассың.

* * *

Атны камчы белән түгел,
Солы белән куала.
Камчы эзе төзәлсә дә,
Җәе йөрәктә кала.

* * *

Ат сөртенми - җир танымый,
Тик чабышка ярамый.
Татар да сүзгә ышанмый,
Үзе татып карамый.

* * *

Атта ут юк, кошта сөт юк,
Юкка үзебез дә тук.
Хөкүмәт үз халкын талый,
Ипи-сөткә акча юк.

* * *

Ерактагылар кешнәшә,
Якын килсә, тешләшә.
Ике алаша ышкынса,
Колыннар үпкәләшә.

* * *

Бер ат ике камыт кими,
Өчне кия хатын-кыз.
Ул - ата да, ул ана да,
Тормышны тарта ялгыз.

* * *

Атларның күрке ял булса,
Хатын-кызның күрке - чәч.
Хәзер чәч тә, өс-баш шундый:
Хатыннар - ир, ир - бикәч.

* * *

«Су» дип кычкырганнан гына
Сүнми янгын, сүрелми.
Башыңны ташка орсаң да,
Комнан аркан үрелми.

* * *

Җүләр дә мөгезле булмый,
Ат та мөгезле түгел.
Яктыны сукыр да тоя,
Сукырның күзе - күңел.

* * *

Очканда карлыгач алдын,
Сайраганда - сандугач.
Оча белгән сайрый белми,
Моң дигәне булмагач.

* * *

Сайрый да, оча да белмәгән
Хәсетлектән буыла.
Сайрый белгән, оча белгән
Илләреннән куыла.

* * *

Кара карга шәп очса да,
Тик карчыга булалмас.
Аны сабынлап юсаң да,
Аккош сыман агармас.

* * *

Йокымсырап ятса шонкар,
Ябалак мәйдан тотар.
Илең күгендә тилгәннәр -
Ауга әзерлән, татар!

* * *

Төнге урманга шом салып,
Нигә ябалак елый?
Ябалак түгел, таланган
Халык ләгънәтен юллый.

* * *

Төн караңгылыкка чумды,
Җәнлекләр посып ятты.
Кан коючы явызларга,
Ерткычларга төн - якты.

* * *

Тукып борыны авырткач,
Тукран да тәүбә итә.
Мең тапкыр тәүбә итсә дә, -
Тамак тәмугъка кертә.

* * *

Карга белән туганлашсаң,
Каргача корылдарсың.
Туган телеңне югалтып,
Үз-үзеңне алдарсың.

* * *

Кыйгачлап очкан саескан
Җәпле койрыгын мактый.
Хаҗәте юк койрык белән
Мактанучылар шактый.

* * *

Сакалым ак дип мактанма,
Акылың барга мактан.
Акыллы Аксакал булсаң,
Мактарлар барча яктан.

* * *

Күз уйнаткан, сүз кабарткан
Ятларга күзең салма.
Су эчерткән, җан кереткән
Идел-дәрьясыз калма.

* * *

Козгыннар башлаган яуга
Шакаллар да ияргә.
Бер бөркетнең үләксәсен
Йолкый ике өермә.

* * *

Тышаулы атны бала да
Утлап йөретә ала.
Явыз кеше богауда да
Канэчкеч булып кала.

* * *

Камчыга ат та чыдамый,
Тамчыга таш чыдамый.
Камчы, тамчы да кешенең
Зиһенен җиңә аллмый.

* * *

Ир-егетнең юлдашы ат,
Моңдашы да тугры ат.
Сүз йөртми, серең әйтми ул -
Сөйләп эчеңне бушат.

* * *

Этнең койрыгын кисүче
Хаксыз булса да хаклы.
Хезмәт хаксыз, хокуксыз да
Калды бөтен ил халкы.

* * *

Үзе туйса, күзе туймый
Гич дәва юк күзенә:
Аңа күрше тавыгы да
Күркә булып күренә.

* * *

Изге күңелле кешене
Нәсыйхәтләү кирәкми.
Үрдәк - бәбкәләрен суда
Йөзәргә бит өйрәтми.

* * *

Иртә уңмаган, кич уңмый,
Коры кулга йон кунмый.
Аллаһ бирмәгән акылны
Базардан алып буллмый.

* * *

Кәкре-бөкре киртәләрдән
Тәртә ясый аллассың.
Кире беткән кеше белән
Юл йөрергә язмасын.

* * *

Ул сарык туны кисә дә,
Бел, үлән ашамасын!
Син тиресен ябынсаң да,
Бүре була аллассың.

* * *

Елан агуы - телендә,
Бүре көче - тешендә.
Ерткычтан да ерткыч сыйфат
Кешенең кай төшендә?

* * *

Агач башларына кунып,
Карлыгач оя кормый.
Карга оясына куеп,
Баласы карга буллмый.

* * *

Язгы бер көн ел туйдыра,
Келәтләр буллмас такыр.
Ялкауларны ачлык белән
Яз сынады күп тапкыр.

* * *

Заман яше үсә бара,
Яман да арта бара.
Арткан яманга юк чара,
Заман һаман бичара.

* * *

Бакалар - елга хуҗасы,
Әтәч - кетәк патшасы.
Безгә һәр җан иясенең
Патшалыгын сакласы.

* * *

Бүре тиресе ябынып,
Бүре була алласлар.
Бүре куй туны киделе...
Куйлар исән калласлар.

* * *

Томанлы иртәдә - төлке,
Буранда бүре йөри.
Аяз көндә җаннар кыеп,
Кеше дигән зат йөри.

* * *

Төлкене хәйләкәр, диләр,
Дөрес сүзме - кем белгән?
Хәйләкәрнең зат тиресен
Абзый түшәмгә элгән!

* * *

Кош аягына җил терәк,
Атның аягына - җир.
Йортның тоткасы - хатын-кыз,
Илнең таянычы - ир.

* * *

Кәй агач ботакка үсә,
Ялагай эт - койрыкка.
Ятка койрык болгаганнар
Сөйрәләр койрыкта.

* * *

Этиең белән горурлан,
Әниең белән мактан.
Эти-әнисен онытканнар -
Бәддогага юлыккан.

* * *

Куркак эт басуга чыкмый,
Ояда шыңшып ята.
Оя ярыгыннан төшкән
Шәүләгә сөяк ата.

* * *

Юк атың белән мактанма,
Сатып ал аны башта.
Таеңның билен сындырып,
Мәтәлеп төшмә ташка.

* * *

Атсыз ир-ат - канатсыз кош,
Иярле ат - ир күрке.
Атыңның холкын белмәсәң,
Калырсың булып көлке.

* * *

Урамда атлары юкның
Исе китми буранга.
Кар-буранда йөргән атлар
Йөри камчы куганга.

* * *

Тау менгәндә сынала ат,
Ат менеп ир дан ала.
Атта чапкан бабамнарны
Алкышлап торган дала.

* * *

Атка атлансаң, ат яхшы,
Җиргә төшсәң, җир яхшы.
Боты кыска - егылып төшә,
Мескенкәйгә җил каршы.

* * *

Атны чыбыркы йөртмидер,
Атны солы йөретә.
Солы ашамаган атны
Җиз авызлык йөгертә.

* * *

Ялы бар дип ябаганы
Яз көне сатып алма.
Ябаган ябага коеп,
Ябагасыз да калма.

* * *

Астындагы атын җайдак
Көннәр буе сизмәгән:
Канатлы атта очканда
Тавалардан эзләгән.

* * *

Бер тарыдан ботка пешми,
Бер каз яз да ясамый.
Вакытында киллмәгән яз
Казларга да ошамый.

* * *

Арыслан кцләгәсендә
Мәхлук җаннар туена.
Дан яраткан зат кырына
Ялагайлар сыена.

* * *

Тән-сөяк авырайса да,
Картлыкка җан сөрелми.
Алтмышта да, җитмештә дә...
Кцңелдә ут сцрелми.

* * *

Берәцләрнең мең куе бар,
Берәцләрнең мең уе.
Мең куй, мең уй бердәм булса...
Булыр ил сабантуе.

* * *

Куй байлыгы, туй байлыгы
Сөбхәналла, туйлар бай.
Никах мәҗлесләренә
Фатыйха бирсен Ходай.

* * *

Акылсызга акыл йокмас,
Тәкә сөзеп тау екмас.
Суына карап - тегермән,
Чүбек тартып он чыкмас.

* * *

Сазлыгында ауный дуңгыз,
Суларда йөзә кондыз.
Кем кондыз хәлендә яши,
Кем сазда, булып дуңгыз.

* * *

Сөтсез кәҗә, кысыр сарык,
Абзарда бакыравык.
Дау куптарып кыртлап йөри
Кукәй саллмаган тавык.

* * *

Кәҗәнең сакалы озын,
Ләкин акылы кыска.
Акыл белән гомер итсәң,
Гомерең үтмәс бушка.

* * *

Бозау талап йөргән дәүләт
Илнең каргышын җыяр.
Тар маңгайлы генераллар
Халкының канын кояр.

* * *

Саранның өсте ялангач,
Тук өйнең мәчесе ач.
Байлык өстендә утырган
Ил халкы ач-ялангач.

* * *

Асыл алманы корт ашый,
Кеше башын сүз ашый.
Кеше башына корт керсә,
Бәсвәсә ашый башлый.

* * *

Кем беленә йөрешеннән,
Кемдер кыланышыннан.
Елгаларның ниндилеге
Күренә агышыннан.

* * *

Сарымсакның исе төмсез,
Суган сукмый елата.
Ләкин кемдер сарымсакны,
Кемдер суган ярата.

* * *

Кишер, шалкан, төпле суган,
Бәрәңге - җир алмасы.
Кәбестә, кыяр бакчасы -
Пенсионерлар акчасы.

* * *

Җир үзен сөйгәнгә - бәхет,
Патшага бирә тәхет.
Ил-җирен сөймәгәннәргә
Тәхет тә бирми бәхет.

* * *

Арыш башак чыгарганда
Арпа да кылчыклана.
Кысыр калган башак исә,
«Мин!» диеп чытыклана.

* * *

Корсаклы борчак кузагы
Соры күлмәген кия.
Җир-күкләрнең көч-куәтен
Җыйдым үземә, дия.

* * *

Дөрес тәрбия булмаса,
Кырда иген дә үсми.
Чүп үләнен йолкысаң да
Басу өстеннән төшми.

* * *

Җир-Анага рәхмәт әйтеп,
Игенче башын ия.
Буш башаклар, күкрәк сугып,
Башларын күккә чөя.

* * *

Ындыр яны буш калганда
Табын яны гөр килә.
Сабан төбе - алтын көшел,
Җиз иләктән он илә!

* * *

Бодай кибәнен ябалар
Арыш саламы белән.
Акыл иясе дан алыр
Каләме Шәриф белән.

* * *

Ашланган җир - кияү көткән
Кәләш шикелле ятар.
Тәрбия җиткән басуда
Тәртә дә чәчәк атар.

* * *

Бия ачуын - тәртәдән,
Тун ачуын - борчадан...
Сыныкны сылтау иткәннең
Башы чыкмас борчудан.

* * *

Мыкләк сыерлар сөзешә,
Аксак атлар тибешә.
Мыкләк сыер, аксак атка
Тыйнак булу килешә.

* * *

Берчак бия кыйммәт тора,
Берчак дөя биядән.
Кирәк чакта һәр икесе
Кыйммәт тора бәядән.

* * *

Ат - бүләк алырга диеп,
Эт сөяк өчен чабар.
Эт белән кодалашканнар
Табында сөяк ялар.

* * *

Әстерханда ат бер акча,
Ерак китсә, мең акча.
Кеше олыгайган саен
Гомер бәясе арта.

* * *

Агыйделнең аръягында
Бер энәгә бер сыер.
Күпне өмет иткәннәргә
Алдану сабак булыр.

* * *

Чыгымлы атыңны сатып, -
Котырган этне атып,
Хыянәт иткән ярлардан
Котылам димә качып.

* * *

Гомерем буе төшемдә
Атка атланып йөрдем.
Дүрт яшемдә биткә типкән
Ат гафуы дип, белдем.

* * *

Масайсак та акыл иясе дип,
Без бер гади адәм баласы.
Гәркем изге эш гамәле белән
Кешелектә истә каласы.

* * *

Табигатьнең кануннары кырыс:
Кеше туа, яши, картая.
Бериш яффак көзгә кадәр яшел,
Беришләре язын саргая.

* * *

Безнең яшәү - күзне ачып йому,
Мәңгелекнең тик бер мизгеле.
Берәү очып, кем мыкәләп бара -
Төрлечәдер гомер тизлеге!

* * *

Тик финишка алдан, арттан булып,
Мөһим түгел килеп җитүе.
Иң мөһиме - нинди ният белән
Дөньялыкта гомер итүе.

* * *

Әйтерсең лә мәңгелеккә килгән:
Дөнья малын ташый йортына.
Гаҗәпләнеп Аллаһ карый булыр,
Кеше дигән нәфес кортына.

* * *

Аллаһның рәхмәте чиксез, -
Кодрәтнең юк чиге.
Кешенең дә очсыз-чиксез
Хыялый күңел күге.

* * *

Бәхетле буласың килсә, -
Тир түгеп тормышың кор.
Кичен тавыклар белән ят,
Иртән әтәч белән тор.

* * *

Адәменә җан иңдереп,
Аллаһ җиргә тараткан.
Адәмнең кабыргасыннан
Хатын-кызны яралткан.

* * *

Этләр үзара талашса,
Соңра инде ялаша.
Ялагайлар хуҗасының
Этенә дә яраша.

* * *

Котырган эт айга өрер,
Ул өрергә ялланган.
Ялагайлар хуҗасының
Табан астын ялаган.

* * *

Теләге кабул ителсә,
Күктән эткә ит явар.
Оясында яткан эткә
Коры сөяк тә ярар.

* * *

Этнең өрмәгәне хәтәр,
Артыңнан килеп тешләр.
Ялагай, күзеңә карап,
Елмаеп этлек эшләр.

* * *

Халыкның хәләл өлешен
Тиҗәләр читкә сата.
Сак этләре калҗа көтеп,
Ояларында ята.

* * *

Өргән этнең муенына
Энҗе-мәрҗәннәр такма.
Җәннәт вәгъдә иткәннәрнең
Телләре - каеш тасма.

* * *

Этлек эшләүне эткә куш,
Эт эткә, эт коерыкка.
Койрык койрык та селкетми
Койрык биргән боерыкка.

* * *

Этләр тешләшеп дуслаша,
Эт тешеннән эт үлми.
Тешләшеп торган кешеләр
Эт тормышын да күрми.

* * *

Өрмәгән эткә таш атма,
Өргән эттән курыкма.
Яман дустан эт яхшырак,
Этең барда таш тотма.

* * *

Этне тугры дус дисәң дә,
Этлек итәсен дә бел.
Майлы калҗага алданып,
Хыянәт итү җиңел.

* * *

Эттәй тугры дустың булсын,
Дустыңнан тугры этең.
Этең, дустың да буллмаса,
Дөньяда яшәү читен.

* * *

Эт симерсә айга өрер,
Үрле-кырлы сикерер.
Маена чыдый алмаган
Төнлә торып үкерер.

* * *

Котырса иясен талый,
Иясе эттән калмый.
Ил учагын тузгыттылар,
Казаны кайный алмый.

* * *

Этләр гомер чиген белә,
Аулакка китеп үлә.
Ил данын саклаган ирләр
Чит җирләрдә күмелә.

* * *

Эт уласа, бүре килә,
Бүрене эт чакыра.
Үзе чакыра, үзе кача -
Бичарага юк чара.

* * *

Хатын-кыз янында - мәче,
Ир янында эт булыр.
Сандугач сайраган җирдә
Эт тә өрмичә торыр.

* * *

Ат җиккәннәр туры китәр,
Морадына ирешер.
Эт җиккәннәр эттән калган
Сөяккә дә килешер.

* * *

Бизәнә белгәнгә бизәк,
Белмәгәнгә ул бизгәк.
Мескен мода корбаннары
Бизгәк чиренә тұзмәк.

* * *

Каз төзәнүдән туйса да,
Кыз бизәнүдән туймый.
Бизәнүсез, төзәнүсез
Табигать тә бит тормый.

* * *

Кар башын - язгы кар ашый,
Елгалар ташый башлый.
Кояшның нурлары җирнең
Күңел кылларын капшый.

* * *

Суык кыш колактан ала,
Сылу йөрәктән ала.
Күршемнең сылу хатыны -
Чәчәкле язгы дала...

* * *

Бала көеге - йөрәктә,
Ир көеге итәктә.
Итәкне бер селкеп кенә
Бушанмый шул йөрәк тә.

* * *

Ире - акча, үзе - ханча,
Тик бала югы хафа.
Кыз чактагы абортларның
Каргышы булды җәфа.

* * *

Кырык хатын тезен кыса,
Бер кыз кияүгә чыкса.
Эби-бабалар шатланыр,
Килен балалар тапса.

* * *

Трамвайда кыз сайлама,
Дин йортында сайлап ал.
Туй-никахлы җефетеңне
Кайнар куеныңа сал.

* * *

Хатын-кызларда - мәхәббәт,
Ир-атта була гайрәт.
Бу байлыкларны сакларга
Балаңны яшьтән өйрәт.

* * *

Арбаны көпчәкләр йөртә,
Кешене язмыш йөртә.
Кемнедер газап чиктерә,
Кемне оҗмахка кертә.

* * *

Ир сыйфаты тәвәккәллек,
Хатын-кызда гүзәллек.
Яман кыз була бер төнлек,
Яхшы хатын - гомерлек.

* * *

Атны да, хатын-кызны да
Әманәткә бирмиләр.
Башында таҗы булса да
Уртак ярны сөймиләр.

* * *

Ил-җир тыныч, илин булсын,
Йортка бәрәкәт иңсен.
Илинлекнең, бәрәкәтнең
Гәркем кадерен белсен!

* * *

Япсаң - эссе, алсаң - суык,
Хатын-кыз юрган кебек.
Җылы сәяк сындырмый ул,
Хатынсыз торма бер ук.

* * *

Яшьлек кадере - бичәдер,
Бичәле бал эчәдер.
Бал эчкәннең исләренә
Сәяркәсе төшәдер.

* * *

Зина кылган хатын-кызның
Таралыр яман аты.
Ир-егетләрне аздыра
Ерылган итәк чаты.

* * *

Язгы тай - төерле коймак,
Көзен инде атлан май.
Сыгылмалы билләрендә
Атланып йөрүе җай.

* * *

Җил-давылдан, кар-яңгырдан
Таш кыялар уала.
Җил-давыллы мәхәббәттән
Газиз башлар югала.

* * *

Ир-егет - илнең шөһрәте,
Утлы-ялкынлы дәрте.
Шөһрәтле егет үстергән
Ил анасы - ил күрке.

* * *

Дәртең, дәрманың булсынга -
Сәламәт булу кирәк.
Бәхетле булу өченгә
Пар килсен ике йөрәк.

* * *

Дәрт ул - дәрья, дәрман - көймә
Көймәсез эшең рәтсез.
Дәртләре ташып торса да,
Дәрмәнсез ирләр хәтсез.

* * *

Кеше алтынны ярата,
Алтын озакка чыдый.
Гомер алтынлы икәнне
Бу тормыш үзе сыный.

* * *

Әгәр кыз булса әдәпле,
Җаны булыр сәдәпле.
Кияүләр чиратка басар,
Эзләп тормый сәбәпне.

* * *

Хатын буеннан билгеле,
Ир - гайрәтле кулыннан.
Икесе дә бу тормышның
Ныклап тотсын ялыннан.

* * *

Ирне ир иткән дә хатын,
Җир иткән дә шул хатын.
Аллаһ хакы белән тиңлә
Анаң, хатының хакын.

* * *

Атасызны кияү итмә,
Анасыз кызны алма.
Бәхетле буласың килсә,
Туй-никахсыз кул салма.

* * *

Хатыны юк - шатлыгы юк,
Хатынсыз гомер - хата.
Бөкре янында - бөкре,
Төз янында төз ята.

* * *

Аш-суның тәме - тозында,
Өйнең яме кызында.
«Намуслы кыз - ил күрке» дип
Язган каен тузында.

* * *

Иясез малны ил алыр,
Ил аллмаса - җил алыр.
Анасын сөймәгән бала
Томадан ятим калыр.

* * *

Олы малыңны нык сакла,
Кече малыңны макта.
Ат - чапкан чакта кадерле,
Кызлар - кыз булган чакта.

* * *

Ата-аналы кыз азмас,
Исеме ерак китәр.
Игелекле варисларын
Чорларга бүләк итәр.

* * *

Кыз байлыгы - саф намусы,
Әдәпле була белү.
Кулдан кулга күчеп йөрү -
Үзеңнән үзең көлү.

* * *

Тауларның күрке кыя-таш,
Хатын-кызларныкы - чәч.
Кыя-ташлар да соклана
Озын чәчләрне күргәч.

* * *

Кызларның дәрте - күкрәктә,
Ир-егетнең йөрәктә.
Күкрәктәге йөрәк дәрте
Сынала куш беләктә.

* * *

Эчке, тышкы матурлыгын,
Батырлыгын да ярат.
Матурлык белән батырлык -
Булсыннар ике канат.

* * *

Алтын - күңел аздырмасын,
Мал юлдан яздырмасын.
Азып-тузып, тормыш бозып,
Йөрергә калдырмасын.

* * *

Кыз күңеле - кызган казан,
Хатын-кыз өе базар.
Кызган-казанлы базардан
Шайтан да куркып сызар.

* * *

Мал-туарны байлардан ал,
Байларда нәселле мал.
Бишектән үк белгән кызны
Гомерлек яр итеп ал.

* * *

Бик бизәнгәннәр биздерә,
Яман кыздан дан китә.
Даны киткән, бизәнгәннәр
Ирләр башына җитә.

* * *

Кыз гомере - каз гомере.
Керфек какканчы уза.
Кыз гомере нәзакәтле
Язмышка кулын суза.

* * *

Кызлар сөелеп сынала,
Тәкатьсезләре - сына.
Кызлыкны булдырып буллый
Ботыңны кысып кына.

* * *

Картлык һәркемгә дә килә
Таягына таянып.
Онык җсә өлкәннәрнең
Ышыгына сыенып.

* * *

Тышы алсу алма кебек,
Ләкин уртасы черек.
Фәхешлектә йөргәннәрнең
Чәселе бара череп.

* * *

Фәхишәләр кәсеп итә
Сылу тәннәрен сатып.
Зинадан туган балалар
Чүплектә кала ятып.

* * *

Бер иш кызлар чәч кистерә,
Озын тырнак үстерә.
Үзен «культуралы» саный,
Үзе эт кебек өрә.

* * *

Төсе сылу булганнарның
Эче убырлы була.
Авызында кызыл теле
Зәһәре белән тула.

* * *

Чиләгенә күрә капкачы, -
Әдәпсезгә - гадәтсез.
Егет кыз табаллмый йөри,
Кызлар йөри егетсез.

* * *

Яшьлекнең челләсе җиткән,
Бар иткәнне пар иткән.
Ишкә ишен гашыйк иткән,
Иш булу бәхет икән.

* * *

Бирәң талап байлык җыя,
Бирәң - ише белән мул.
Байның типкәсе булганчы
Ярлының иркәсе бул!

* * *

«Оясында ни күрсә,
Очканда да шул булыр».
Козгын оясында үскән
Козгын гадәтен куыр.

* * *

Дөньяны алтын бизәми,
Дөньяны акыл бизи.
Акылны алтын бизәсә,
Кеше тәкате тузми.

* * *

Саклы кырны кырау аллас,
Игеннәр чәчәк атар.
Тырышлар камыр басканда
Ялкаулар акыл сатар.

* * *

Малны тапкан кеше бага,
Утыны бар - мич яга.
Мал тапканның, мич якканның
Бәхете канат кага.

* * *

Дәү дөяне күрмәгәннәр
Бак төймәне күрмидер.
Хәсрәт чигеп йөрмәгәннәр
Дөнья хәлен белмидер.

* * *

Сигез сарык асраганчы,
Бер симез үгез асра.
Сарыклар дер-дер килгәндә,
Үгез бүре качыра.

* * *

Чабыш атларын зурлыйлар,
Ябаганы хурлыйлар.
Хурлаучылар ябаганың
Тырнагына тормыйлар.

* * *

Көтүчесе кырын ятса,
Сыерның сөте кими.
Халкы хәерче Илбашы
Идарә итә белми.

* * *

Ялгыз усак яфраклары
Җил исми дә калтырый.
Бу дөнья үзе дә парлы,
Ялгызлык берни тормый.

* * *

Маңгай күзе күрмәгәнне
Күңел күзләре таба.
Күңел күзенең чиге юк, -
Хыял алдыннан чаба.

* * *

Ыңгырашканда дус кирәк,
Дип әйтә күргән-белгән.
Иш ише белән гайрәтле,
Тычкан тишеге белән.

* * *

Акылсыз тели тормышны
Җир белән тигезләргә.
Бер пычак җитә бер көтү
Баш бирмәс үгезләргә.

* * *

Җинаятьче патшаның да
Эзенә бер басалар.
Чалгач корбан тәкәсен дә
Аягыннан асалар.

* * *

Дулаган диңгез дулкыны
Чыгып ята ярына.
Язга чыккач агачлар да,
Чүп-чарыннан арына.

* * *

Илнең даны - игелекле
Яхшы ата баласы.
Ил тормышының торышы -
Яхшы тунның якасы.

* * *

Ара ерак агай-эне
Күңел белән берләшә.
Күршедәге бертуганнар
Көнләшүдән әрләшә.

* * *

Бүген кадерле туганың
Иртәгә - әче суган.
Әйтерсең лә бу туганнар
Туганга каршы туган.

* * *

Туган туганнан көнләшә.
Ашка дус-ишен дәшә.
Үзәк өзелгән чакларда
Дус-иш буллый янәшә.

* * *

Агай-эне, бертуганны
Бер үк ана яралткан.
Ана сөте агартканны
Тана сөте каралткан.

* * *

Тулышы барның куышы,
Үз йорты, җире булсын.
Агай-энеләр берләшсен,
Еракта якын торсын.

* * *

Бармак араларына бит,
Теләсәң дә ит үсми.
Туганнар арасында да
Тиктомалдан җил исми.

* * *

Ир-атларның горурлыгы
Ил-җирне яклавында.
Хатын-кызның зирәклеге
Гаиләсен саклавында.

* * *

Ир-егетләр кызлар сөя,
Кызлар ярата байны.
Байлар да баета аллый
Акыл-фигыле сайны.

* * *

Ир-егет гаиләсен сөя,
Яшь ватаны өчен.
Гаиләсенә, ватанына
Багышлый бөтен көчен.

* * *

Кемдер әйткән: «Бу дөньяны
Матурлык коткарыр», - дип.
Матурлык - сабый баланың
Елмаю-көлүе бит.

* * *

Вакыт узмый, без узабыз
Вакытның үзен узып.
Сәгать телен күчерудән
Тәүлекне буллый сузып.

* * *

Кемдер үзен акыллыга саный,
Үзе көн дә булыр исерек.
Сүзләренең рәте-чираты юк,
Җилгә оча булып төкерек.

* * *

Үзен чаккан еланны ул
Туганыннан үтертә.
Канкардәш, нәсел-нәсәпне
Үзара дошман итә.

* * *

Үпкәләмә көзгегә син,
Авызың кыек булгач.
Туган телсез дә калырсың
Ясин догасы кылгач.

* * *

Бинаһая ил байлыгын
Кемдер казнага салган.
Халык ачлыктан интегә,
Эшсез, өлешсез калган.

* * *

Җиргә аяк баскан көннән бирле,
Яшәү өчен кеше көрәшә.
Дин белән фән бердәмлеге генә
Аллаһ рәхмәтенә ирешә.

* * *

Ераста калды, ераста
Аҗаган балкышлары.
Кайда яшенле яшьлекнең
Ялкынлы алкышлары?

* * *

Һәрнәрсәнең үз вакыты:
Үсә, пешә, өлгерә.
Тик ботагында эленеп,
Өлгергәннәр тилмерә.

* * *

Чамлы - затлы, киркәм сыйфат,
Дан әҗерен алырсың.
Тәкәбберлек башлык булса,
Хур-мәсхәрә калырсың.

* * *

Оҗмахны читтән эзләмә,
Туган җир - үзе оҗмах.
Адәм белән Хава кебек,
Син берүк кылма гөнаһ.

* * *

Мәңгелеккә яралтылган
Без Галәмнең матдәсе.
Җисемебез үзгәрсә дә,
Галәм - җаннар мәркәзе.

* * *

Мәхәббәт ул - илаһи хис,
Кеше - шул хис җимеше.
Илаһи хистән дә көчле
Үз-үзен җиңгән кеше.

* * *

Әй, хатын-кыз! Табигатьнең үзен
Сыйдыргансың күңел түреңә.
Син тереклек шәһе, язлар назы,
Җәннәт түре булсын үзеңә.

* * *

Берәүнең күзләре сөйли,
Берәүнең әйткән сүзе.
Кемнең кем икәнен ача
Бер сүз, бер караш үзе.

* * *

Сәяркәләр дәрте өтә,
Татлы шәраб исертә.
Майлы бәлеш тә туйдыра,
Күпкә китсә кикертә.

* * *

Европага яуга чапкан
Мәшһүр Атилла бабам:
«Бердәм булыгыз!» васыятен
Хәтердә тотыйк һаман!

* * *

Тормышта төрле чак була, -
Ятлар да куя ярап.
Тик вакытлы булган ятлар
Тормас микән җан сорап?

* * *

Хыянәтче хатын-кызның
Ялганы күз яшендә.
Мең тапкыр тәүбә итсә дә,
Ул һаман үз эшендә.

* * *

Ир белән хатын талаша -
Күршеләргә тамаша.
Ир-хатын ара бәхәсләр
Тышәк аша яраша.

* * *

Хәзерге заман килене
Кайнанасын кайната.
Кайнана - килен эшендә,
Килен тышәктә ята.

* * *

Яшәүнең кадерен белсәң,
Бәһасе юк гомернең.
Сукыр бер тиен дә тормый
Кадере юк гомернең.

* * *

Атасы бар - гүзәл чәчәк,
Анасы бар - сихри гөл.
Зинадан туган балалар
Ата-аналы түгел.

* * *

Ир бала - сөт, кыз - сөт өсте,
Онык - сөтнең каймагы.
Улың, кызың, оныкларың
Буллмасын базар малы.

* * *

Сатлык җаннар җирне сатар,
Куркак хаким ил сатар.
Илсез-җирсез калган халык
Эт типкесендә ятар.

* * *

Балалар - ата-ананың
Аллаһыга шөкере.
Оныкларның оныклары -
Буыннарның күпере.

* * *

Ир бала - йортның терәге,
Кыз бала - өй бизәге.
Егет тә, кыз да ил-җирнең
Көянтәсе, чиләге.

* * *

Татарның хатын-кызлары
Чит халыклар үрчетә.
Ир-егетләр ятлар коча,
Үз милләтен кимсетә.

* * *

Тәңкәләре ялык-йолык итә
Суда уйнаклаган балыкның.
Кешеләрне нәфес колы итә
Ялтыравы сихри байлыкның.

* * *

Чәни генә энәне дә
Күгәрүдән эш саклый.
Сапласаң, балта да җирдә
Күгәреп аунап ятмый.

* * *

Аягыңа чолгау итмә,
Асыл ефәк - бүз түгел.
Тәнен сатып йөргән кызлар
Ана булыр кыз түгел.

* * *

Күләгәсен генә үлчәп,
Осталар күлмәк кисми.
Күләгәле тау астында
Чәчәк-гөлләр дә үсми.

* * *

Олыда да, кечедә дә
Йодрыгы кадәр йөрәк.
Ғәркемгә дә кояшка тиң
Игелекле йөрәк кирәк.

* * *

Дөньяның кайга-шатлыгын
Кичерә тиҙем йөрәк.
Холыкка да, йөрәк кебек,
Тиҙем булырга кирәк.

* * *

Күрше хакы - Алла хакы.
Күршеләр тату торсын.
Хатыны чибәр ирләрнең
Күршесе сукыр булсын.

* * *

Алыпсатар хатыннарның
Ирләре өйдә ята.
Ғазар малына әйләнсә,
Хатын-кыз үзен сата.

* * *

Сөйкемле уңған киленнәр
Йорт-ҙирне күркәм итә.
Ипсез каенсеңелләр дә
Ҙиңгәйгә охшап китә.

* * *

Акыллы кыз үзен сатмый,
Кызлык намусын саклый.
Балалары, оныклары
Йөзенә кара яҡмый.

* * *

Туйга кадәрле - кызыңны,
Туйдан соң өең сакла.
Ата-баба аманәтен
Ғомерең буе акла.

* * *

Энә илне киендерә,
Үзе һаман ялангач.
Эшсез калды... Дөньяларны
Кризис кочып алгач.

* * *

Бертуганыңны биздерсәң,
Туган туғелләр сизә.
Мал кардәшлеге югалса,
Жан кардәшлеге бизә.

* * *

Күршең гайбәтче булганда -
Диварның колагы бар.
Тормышыңны мәхшәр итәр,
Киң дөньяң да булыр тар.

* * *

Хыянәтче - җинаятьче
Коръәндә дә ул шулай.
Ике дөньяның җәзасы
Хыянәтчегә кулай.

* * *

Гомер итәр өчен кеше
Ризыктан ала көчне.
Ашаганы хәрам булса,
Сөт тә хасталар эчне.

* * *

Итнең майсыз җирен аша,
Симез җирен эткә бир.
Тәнең имәндәй нык булыр
Эченә кераллмас чир.

* * *

Башкаларда гаме юкның,
Яшәвенең тәме юк.
Гаме, тәме юк кешенең
Тормышының яме юк.

* * *

Тауның билгесе - таш була,
Йорт билгесе - аш була.
Йортында ашы юкларның
Куенында таш була.

* * *

Беткә ачу итеп тунын
Яга тик җүләр кеше.
Бет беткәннән дәнья бетми,
Тик арта җүләр ише.

* * *

Дуңгыз ите майлы була, -
Авырттырыр үтеңне.
Сыер, сарык ите аша, -
Кызартмаслар битеңне.

* * *

Тәүлекнең биш вакытында
Бар намаз укыр вакыт.
Әдәпле итәсең килсә,
Балаңа намаз укыт.

* * *

Казанның капкачы төшсә,
Ач этләр килеп җитә.
Кешеләрдән оят китсә,
Эттән дә азып китә.

* * *

Черек җимеш җиргә төшә,
Үтмәс пычак кул кисә.
Байлыкка табынган илдә
Пычак тотканнар үсә.

* * *

Кыланышы кырга сыймый,
Акылдан яза эчсә.
Тиресеннән чыгар иде,
Керү әмәлен белсә.

* * *

Тау күрке - таш, өй күрке - аш,
Аш булган өйдә яраш.
Бер тәлинкә ашка тормый
Энҗе-мәрҗән, асылташ.

* * *

Казаның кайнамас, әгәр
Син үзең кайнамасаң.
Ашыңны этләр ашарлар,
Капкачын карамасаң.

* * *

Тәрбия ул - әдәп-әхлак,
Холкыңны күркәм итмәк.
Яшәүнең мәгънәсе - хезмәт,
Икмәктә - бөтен хикмәт.

* * *

Карт бәркетләр тычкан тота,
Карт ирләр аш кайната.
Тычкан тоту, аш кайнату,
Үй-фикерләр уята.

* * *

Икейөзле үткен хәнҗәр
Үз сабын үзе юнмас.
Икейөзле кеше юна, -
Үз сабым диеп тормас.

* * *

Ашлы өйдә бәрәкәт бар,
Гәркемнең күңеле хуш.
Хәрәкәттә бәрәкәт бар,
Хәрәкәт - бәрәкәт куш.

* * *

Гәрнәрсәнең тамгасы бар:
Юмартлык тамгасы - аш.
Юләрләрдә - җан өзгеч сүз,
Акыллыда - гамьле баш.

* * *

Кәкресе дә, турысы да
Агачның тигез яна.
Чүлмәкне кая куйсаң да,
Төбеннән эзе кала.

* * *

Хаҗга дегет чиләге дә
Арбага таксаң бара.
Дегеттән арыну өчен
Ут-ялкын аңа чора.

* * *

Чиләкнең төбе тузса да,
Ян-ягы таза кала.
Тик инде хуҗа аңарга
Чүп-чарын гына сала.

* * *

Башы булганның ашы бар,
Ашлы йортның яме бар.
Аш кайнатып, кош сайратып
Яшәүләрнең тәме бар.

* * *

Йомык кеше, - ябык казан,
Үз эчләрендә кайный.
Сөт шикелле күперә дә,
Ташый, каймагы каллый.

* * *

Үткеннән үткен кылыч та
Үз кынын үзе кисми.
Азгын күсе өере дә
Кораб идәнен тишми.

* * *

Буш капчык утыра аллый,
Тулы капчык бөгелми.
Милли рухы, хисе булган
Халык ятка бирелми.

* * *

Кызыл төс күргән үгезнең,
Башы-күзе акая.
Кеше, үгездән дә узып,
«Ура!» диеп акыра.

* * *

Аш-су кайнаган казанның
Тыш ягын корым сара.
Ак перчатка кигәннең дә
Күңеле була кара.

* * *

Сәясәт - пычрак эш-гамәл,
Мәгълүмат, гайбәт җыя.
Сәясәтчеләр гонаһын
Халык күз яше юа.

* * *

Аллаһка ышана, юкмы...
Гәркемнең кальбе азат...
Тик һәркемнең Алласы бар,
Кеше - табынучы зат.

* * *

Тулы чиләк төз утыра,
Суы тын гына тора.
Буш кеше буш чиләк кебек, -
Кагылсаң, шау куптара.

* * *

Ашына күрә кашыгы,
Кашыкка лаек ашы.
Хуш ис бөркеп утырган аш, -
Табынның йөзек кашы.

* * *

Гәркемнең үз шөгыле бар:
Исәпнең бар хисабы.
Ярманы он итү өчен
Кирәк киле кисабы.

* * *

Гәрнәрсәнең бар калыбы,
Кешенең - үз калебе.
Тормышта кануни яшәү -
Ул тереклек таләбе.

* * *

Ертыкның авызы ерык, -
Ертык тишектән көлә.
Ертыктан тишек көлдертү
Әмәлен Мәскәү белә.

* * *

Исәпкә бар, хисапка юк
Сансызларга сан тиде.
Сайлаучы дип исемлеккә
Керетү кирәк иде.

* * *

Ир тавышлы хатын-кызлар
Ир куәтенә ия.
Хатын-кыз тавышлы ирнең
Дәртенә төшкән көя.

* * *

Пешекче оста булмаса,
Коймак төерле була.
Кыныннан чыккан кылычның
Йөзе кан белән тула.

* * *

Намусыңа пычрак яксаң,
Тәнгә, җанга куна кер.
Юыллмый яткан кер белән
Уйнашчы хатын да - бер.

* * *

Авыр сүзне җан күтәрми,
Керне күтәрми сафлык.
Күңеле ак, калебе пакь
Затлар буллыйлар сатлык.

* * *

Язын кайтып, көзен киткән
Киек казлар юл салган.
Кешеләр юл салу серен
Казлардан отып алган.

* * *

Аксак кеше күп йөри, дип
Хак әйтә безнең халык.
Аксап йөреп хаклык эзли,
Сугышта гарип калып.

* * *

Үтекченең үтеге бар,
Чүтекченең - чүтеге.
Чабата киеп йөргәннәр
Була адәм өтеге.

* * *

Анага газиздән газиз
Баласы - бәгырь үте.
Каргыш-рәнҗүләрдән саклый
Баласын ана сөте.

* * *

Бер генә җан иясе дә
Хаксыз дөньяга килми.
Берәү дә ризыксыз тумый,
Ризыгы бетми үлми.

* * *

Бу дөньяга адәм заты
Ялангач килеш килә.
Гомер буе байлык җыя,
Чыптага ятып үлә.

* * *

Әй, әйләнеп тора заманалар,
Карап-карап тирә-ягына.
Урак-чыкеч өсләрендә әнә
Ике башлы козгын кагына.

* * *

Ул, имеш, әбине яшь кыз,
Яшь кызны әби итә.
Кыз буучы шарлатаннар
Кеше башына җитә.

* * *

Аш кадерен ачлар белә,
Киемнекен - ялангач.
Кеше дә тормыш кадерен
Белә картлык башлангач.

* * *

Хатын-кыз - өйнең дәүләте,
Ул Аллаһның нигъмәте.
Дәүләтле, нигъмәтле булу -
Ир-егетнең нәүбәте.

* * *

Юрга - атларның солтаны,
Ул гаярь ирләрнеке.
Яшә, тормышны иярләп,
Тормыш - тәвәккәлнеке.

* * *

Берәүләр туңып калтырый,
Ә берәүләр - куркудан.
Койрык болгаучы ясыйлар
Калтырап торганнардан.

* * *

Бик чишенмә, таралырсың,
Кыз тиеп каралырсың.
Бер каралганнар агармый,
Ала-кола калырсың.

* * *

Баласы яхшы атаның
Башы күкләргә тия.
Яхшы ата баласына -
Ислам әхлагы ия.

* * *

Апа-сеңел - әни түгел,
Канкардәшләр булса да;
Башларында асылташлы
Таҗ ялтырап торса да.

* * *

Кияве белән кызының
Урыны һәрчак түрдән.
Килене белән улының
Ишеккә якын җирдән.

* * *

Мал-мөлкәтең бар чагында
Әйләнәңдә дус-ишләр.
Шул дус-ишләр дошманыңнан
Катырак итеп тешләр.

* * *

Ата-ана көн-төн эштә
Буллмак булып бәхетле.
Баласы - сәрхуш, наркоман...
Кайдан алсын бәхетне?

* * *

Берәүнең бай абыйсы бар,
Ак яулыклы апасы.
Эти-әнисез ятимгә
Кайсын сайлап аласы?

* * *

Энҗе-мәрҗән, асылташлар
Бизәсә дә башмакны, -
Гәркемнең дә үз урны бар,
Шаһ итмиләр ахмакны.

* * *

Ямаулы ертык беленә,
Капласаң да күренә.
Кызлыгы ертык кызларның
Кермә икән түренә.

* * *

Тешәкле кеше тешәнер,
Икмәге бар күшәнер.
Тешәкле, икмәклеләрнең
Нәселләре ишәер.

* * *

Ямауга калган әйберләр
Иске әрҗәдә тора.
Яманга калган кешеләр -
Ни чәчсә, шуны ура.

* * *

Хисләрнең төрлесе була:
Бар иртә суынганы.
Талаклаша туйга кадәр,
Секста сыйланганы.

* * *

Сату иткәч базарда утырып,
Кичен йөрде чәркә тутырып.
Дус-иш белән керделәр «колхоз»га,
Сыер сыйды уймак авызга.

* * *

Иркәсен ул: «Татлы аллам» диеп,
Уч төбендә тотып яратты.
Багалмасы кортлы булган икән,
Тешләде дә читкә ыргытты.

* * *

«Җиләк кирәк миңа», - диде әни,
Тәвәккәллəп киттем базарга.
Карбыз «йоткан» җиләк кебек кызны
Килен итеп бирдем аңарга.

* * *

Белеме дә бар шикелле...
Корсак цскән, тамак тук.
Тик мыекка чорнаклык та
Бер акыллы сүзе юк.

* * *

Ир-ат ут-ялкынлы булса,
Хатыны төтен булыр.
Араларына кергәннән
Тик кисәү башы калыр.

* * *

Акыллы ир тормыш кора,
Үз көнен цзе кирә.
Кеше сүзе белән йөргән
Хурлык сазына керә.

* * *

Бер яхшы затка - бер яман,
Бер галимгә бер надан.
Белем-гыйлемлe булуда
Тәрбия йөри алдан.

* * *

Ир канаты - җигелe ат,
Кыз канаты - парлы кош.
Төштә күрсәм, күңелем хуш,
Уянам - күңелем буш.

* * *

Искиткеч гүзәл йөзләр бар,
Тик ул гүзәллек түгел.
Эш-гамәлең гүзәл булсын,
Күңеледә чәчәк-гөл.

* * *

Дәүләт тотуы җиңелме?
Хатын тоту җиңелме?
Тәхет иясе ирләр дә
Хатыныннан җиңелде.

* * *

Чал Иделнең дан-шөһрәте -
Иңләп аккан суында.
Ил агасы ирнең даны
Мәйдан тоткан улында.

* * *

Хан ханлыгы, хан хатыны -
Икесе ике дәүләт.
Ханлыкны - кануннар тота,
Хатынны - назлы хикмәт.

* * *

Тауга карап тау булып булмастыр,
Таулар алар миллион гасырлык.
Башларында мәңгелек кар яткан
Тауга менү - үзе батырлык.

* * *

Бер өйдә булса ике кыз -
Берсе энә, берсе без.
Берсе яз булып балкыса,
Икенчесе салкын көз.

* * *

Ат беленәдер тешеннән,
Кыз күренер тышеннән.
Затлы кызның йөзе көләч,
Чур сибелә эченнән.

* * *

Кычыткан сабагын урап,
Эт эчәгесе цсми.
Үзең бәреп төшермәсәң
Бер басымчак та төшми.

* * *

Кыз күңеле - кырык карта,
Зиһенне адаштыра.
Йөзе ак диеп алданма,
Аклык та саташтыра.

* * *

Матур алма кортлы була,
Матур кыз кызыктыра.
Матур алма, матур кызлар, -
Күңелне азындыра.

* * *

Тән матурлыгы - кан белән,
Гәүдәнеке җан белән.
Аллаһ кан биреп, җан өреп,
Адәмгә яшәү биргән.

* * *

Матурлык ул туйда кирәк,
Акылың белән мактан.
Тик тәнең җәфа чикмәсен
Йөгәнсез матурлыктан.

* * *

Бозыклык ишектән керсә,
Сафлык тәрәздән чыга.
Бер көктә ике ай буллмый,
Дөньяга - Галәм хуҗа.

* * *

Гөлчәчәкләр җирнең күрке,
Гүзәл кыз - илнең күрке.
Кыз күңеле - кылдан нечкә,
Өзелсә - булыр көлке.

* * *

Сабагында пешкән тәмле,
Кортлысы җиргә төшә.
Кызлыгын югалткан кызның
Кызының бите пешә.

* * *

Камышлы җир - көмешле җир.
Җиләс җирдә җимеш күп.
Бите матурга кызыкма,
Матурлыкта хәйлә күп.

* * *

Кызны күзең белән түгел,
Колагың белән сайла.
Сөйдергән, биздергән дә - тел,
Әйткән сүзләрен тыңла.

* * *

Зәйтүн гөле мактаулы гөл,
Нәркис гөле - назлы гөл.
Гөлләр чәчәкләрен коя,
Назын койласын күңел.

* * *

Гүзәлдән-гүзәл гөлләрнең
Тамырларына кара.
Гөлләргә дә гүзәллекләр
Нәселдән күчеп бара.

* * *

Матурның акылы такыр,
Чытлыкның эче кортлы.
Ялагай кыз юха була,
Көнченең күзе - утлы.

* * *

Суклакта үскән агачның
Тамырын балта чаба.
Балта тоткан палачны да
Әҗәле эзләп таба.

* * *

Бала-бала, дия-дия,
Янган утка керерсең.
Үзеңнең кем икәнеңне
Балаң үскәч белерсең.

* * *

Явыз патша яуга чабар,
Миллионлаган баш куяр.
Гаепсез халкын гаеплэп,
Төрмә-ГУЛАГка җыяр.

* * *

Игелекле ил хуҗасы
Илендә базар ясар.
Сәүдә иткән ил-халыкны
Бәрәкәтле мал басар.

* * *

Сау хатынны ире сөя,
Бай ирне иле сөя.
Ире сөйгән, иле сөйгән
Хөрмәт таҗына ия.

* * *

Тулышы барның өлеше,
Куышы бар бу җирдә.
Бәркет оясы - кыяда.
Бака рәхәте - күлдә.

* * *

Яман килен, ирмәкүк кук
Мәкер җәтмәсе ирер.
Үзарада сүз йөретер,
Өйгә вәсвәсә керер.

* * *

Буласының буыныннан,
Йөрешеннән беленә.
Көтүченең дә кеммеге
Таягыннан күренә.

* * *

Каты серкә кабын ерта,
Зәһәре үткә үтә.
Гайбәтченең нахак сүзе
Дусларны дошман итә.

* * *

Илдә төрле кеше яши,
Ашлык та юк кибәксез.
Ач кибәкне җил очыра, -
Бездә картлар кирәксез.

* * *

Икмәксезнең иманы юк,
Имансызның дене юк.
Денсез, имансыз кешенең
Рәхәт күргән көне юк.

* * *

Акыллы сүз кодрәтеннән
Чыныгадыр корыч та.
Хикмәтле сүз ирешкәнгә
Ирешаллмый кылыч та.

* * *

Яхшы сүз ачуны баса,
Яктылыктан төн кача.
Кылыч ачаллмаган телне
Ипле-татлы сүз ача.

* * *

Гәркемнең холык тамгасы,
Уй-ниятe күзендә.
Иманлы, имансызның да
Үз мөһере - йөзендә.

* * *

Солы ашаган ат армас,
Ашамаганы бармас.
Хутсыз хөкүмәт арбасын
Ач халык тарта аллмас.

* * *

Татар барда хәтәр бар дип,
Куркыталар халыкны.
Юри суны болгаталар
Тотар өчен балыкны.

* * *

Аты барның канаты бар,
Дигән безнең бабалар.
Нигә атсыз, ник канатсыз
Туган телсез балалар?

* * *

Гомер буе хыялландым
Хәр Идел-йорт булыр дип.
Бу бәхетне мин күрмәсәм,
Варисларым күрер бит!

* * *

Майлы ботка, симез калҗа
Һәфесне ымсындыра.
Көчле дигән затларның да
Рух куәтен сындыра.

* * *

Ай, кояш, йолдызлар балкып,
Яктылык бөрки җиргә.
Аллаһының Әманәте
Бәрәкәт булып иңә.

* * *

Явыз сәрхүшнең өендә
Юк ярмасы өйрәлек.
Дан-дәрәҗә сөйгәннәрне
Харап итә тупәлек.

* * *

Коры кашык авыз ерта,
Майлый белергә кирәк.
Тинтәкне дә тупә итеп
Сайлый белергә кирәк.

* * *

Мәхәббәт - серле могҗиза,
Мәхәббәт - сихри ләззәт.
Мәхәббәт - акыл, зирәклек,
Ул гомерлекле гыйззәт.

* * *

Сыйлашырга, сөйләшергә
Дус-ишләр килеп йөрмәк.
Авыр чакта дус-иш түгел,
Үз туганнарың терәк.

* * *

Чын шигырь йөрәк янганда
Ялкын белән языла.
Ялкын сүнеп төтен басса,
Хак-хакыйкать бозыла.

* * *

Дөнья шулкадәр дә серле, -
Хикмәт эчендә хикмәт.
Хикмәтле бер серне ачу, -
Асылташтан да кыйммәт.

* * *

Эшләгән затка көч кирәк,
Тик ятканга ни кирәк?
Халык ач-ялангач калды,
Эшле-ашлы ил кирәк.

* * *

Татар татарлыгын итә, -
Хан булырга ярата.
Каш ясыйм дип күз чыгара,
Сукырлар сазга бата.

* * *

Нәфес кешедән кол ясый.
Ул - шайтаннар коткысы.
Акыллы затлар кулында
Нәфес тормыш тоткысы.

* * *

Кешене язмышы йөртә.
Ул ашата, эчертә.
Ләкин язмышка ышанып
Торма басып бер читтә.

* * *

Бервакыт һавада рәхәт,
Бервакыт суда җайлы.
Каймакның да өсте тәмле,
Коймакның асты майлы.

* * *

Кышын әйбәт, җәен рәхәт
Үзсын дисәң көннәрең, -
Кышын кияр туның булсын,
Җәен эчәр әйрәнең.

* * *

Табигатьнең үз кануны:
Белү кирәк чаманы.
Борчак күпме сикерсә дә,
Ватa аллый табаны.

* * *

Кәкре агач туры яна,
Түр төзәтә явызны.
Явызлык ачлый авызны,
Ризык ача авызны.

* * *

Әүвәл күңелеңне җылыт,
Өйрәне өйдә суыт.
Якын туганнар ягыннан
Киллмәсен зыкы суык.

* * *

Каш арасына йон үсми,
Бармак арасына ит.
Арага дошман кераллмас -
Туганнар буллмаса чит.

* * *

Көзен табын уртасында
Яз көне «пешкән» бәлеш.
(Язгы көн ел туйдыра дип,
Әйтүләре бик дөрес).

* * *

Ризыгы бернең - сере бер,
Сере берләр күп белер.
Канкардәшләр арасында
Туганлык алдан йөрер.

* * *

Аш ашалды, яшь яшәлде,
Мич сүнде, әйрән түнде.
Булганның кадерен белеп,
Очлыйсы калды инде.

* * *

Туфракка алтын чәчкәннән
Ул иген булып үсмәс.
Хәтта алабута кебек
Икмәк булып та пешмәс.

* * *

Гали пәкесе шикелле
Булса да кылыч үткен,
Ипи-тоз алдында - ул да
Көч-куәтсез, бер мескен.

* * *

Җиләк-җимешләр шикелле
Икмәк агачта үсми.
Аллаһ бирмәсә, акыл да
Күктән өзелеп төшми.

* * *

Аллаһка мең рәхмәт әйтәм
Исәнлектә көн күрсәм.
Кояш тирәли әйләнгән
Җир-ана кебек йөрсәм.

* * *

Балта, пычакка үрелмә,
Бәхәснең төбен белми.
Хикмәтле сүз - яхшы илче,
Ул кан-яшь алып килми.

* * *

Бал өстенә тоз сипмиләр,
Кыярга бал якмыйлар.
Тәкәгә мөгез чыгарып,
Аткa койрык такмыйлар.

* * *

Сөттә саулык, иттә куәт,
Майда - файда, бәрәкәт.
Майдан, сөттән, иттән зякәт
Биргәннәрдә мал-мөлкәт.

* * *

Сөт, катык - йөрәккә ятык,
Сихәтлән көн дә эчеп.
Катык, сөт эчкәннәр яши
Сырхаусыз гомер кичеп.

* * *

Балга мансаң балтаны да,
Бәлкем, буладыр йотып.
Әнә берәү тормыш кормак
Миче өстендә ятып.

* * *

Байлар симез калҗа ашый,
Ялагай табан ялый.
Таланулардан сыкранып,
Үксез табигать елый.

* * *

Дөньяның хуҗасы - Акыл,
Акыл тегермән тарта.
Теле тегермән тартканның
Тегермәнен җил вата.

* * *

Нәселе затлы анадан
Нәселле дәвам туа.
Җиләк-җимешләр эченә
Җир-кыкләр тәме тула.

* * *

Алманы ачы булса да
Чыгарып ташламыйлар.
Мәхәббәт татлы, ләззәтле,
Тик аны ашамыйлар.

* * *

Шикәр комы, көрпә оны
Бер-берләренә охшаш.
Шикәр комы - табын яме,
Көрпә - хайваннарга аш.

* * *

Ил-җир базарга әйләнде, -
Бар нәрсә дә сатыла.
Акыл сатканнар тотыла,
Ил сатканнар котыла.

* * *

Ит ашасаң - көчең арта,
Су эчсәң - эчең калка.
Тырәләр ит-май ашыйлар,
Сөяк-санак - халыкка.

* * *

Сөйгән ярын югалтканның
Сагыш телә бәгырен.
Ялгыз интеккәннәр белә
Бергә яшәү кадерен.

* * *

Исемеңне бер каралтсаң, -
Кара ясыйлар актан.
Кем гаепле - ул гаепле?!
Гаепсез җавап тоткан.

* * *

Наркоманлык һәм сәрхушлек -
Агылый-тагылый кук.
Бусагаңнан берсе керсә,
Икенче афәтен көт.

* * *

Ут дигәннән авыз пешми,
Саламнан күмер төшми.
Тирләп-пешеп эшләмәсәң
Кырда камыл да үсми.

* * *

Уйсыз-фикерсез яшәүнең
Мәгънәсе, кызыгы юк.
Пыскып янган учакта да
Төтен күп, кызуы юк.

* * *

Шәмнең яме шәмдәл белән,
Хатынның - бала белән.
Тел тегермәне тартканның
Белгәне: фәлән-төгән.

* * *

Яман хуҗа йортын ташлап,
Чит җиргә чыгып китәр.
Ил башында яман торса,
Дәүләт башына җитәр.

* * *

Ана күңеле балада,
Баланыкы - далада.
Ана, бала яши хәзер
Даладагы калада.

* * *

Авызыңны бер пешерсәң,
Салкын суга өрәсең.
Иске йортыңның кадерен
Яңасында беләсең.

* * *

Сатлык - илне уптым сата,
Куркак хаким - өлешләп.
Ихтыярсыз халык тора
Теш кысып, ирнен тешләп.

* * *

Гәрнәрсәнең үз җае бар,
Ташка казык какмыйлар.
Йортсыз-җирсез чегән кебек,
Гәр язда тун сатмыйлар.

* * *

Бар дөньяны иңләп-буйлап
Кризис яулап алды.
Кешеләр, шайтаннар кебек,
Эшсез, өметсез калды.

* * *

Ач күзгә казан астырма,
Туңганга ут яктырма.
Ут күрмәгәннәр ут күрсә,
Туя белмәс яктыга.

* * *

Майлый белсәң, ришвәт бирсәң,
Депутат булу җиңел.
Башкалар аннан ким түгел,
Кесә ягы тиң түгел.

* * *

Теле телгә йокмаганның
Тел очында азыгы.
Телен тыя белмәгәннең
Баш очында казыгы.

* * *

Өметтә илаһи көч бар,
Өметсезгә дөнья тар.
Кешене өмет яшәтә,
Өмет барда - яшәү бар!

* * *

Ерак гасырлар түреннән
Ата-бабалар дәшә:
«Җир-суыңа хуҗа булып,
Илендә иркен яшә!»

* * *

Икмәк бар нәрсәгә дә баш,
Башакта - дәүләт көче.
Тик дәүләте тук булганда
Хәр яши ала кеше.

* * *

Борчу, кара кайгы килсә,
Ак каенга юрама.
Каен Хак Тәгалә түгел,
Аңа гозер юллама.

* * *

Тормыш ул - капма-каршылык.
Яхшы-яман көрәше.
Хәерле, изге эшләрнең
Кабахәтлек - көндәше.

* * *

Дөньяда бар матди байлык,
Бар янә рухи байлык.
Миһербанлыкны йотмасын
Саранлык-комагайлык.

* * *

Алтын табак тоттырдылар,
Бирделәр көмеш кашык.
Тик дуңгыз тагарагына
Булган икән шул гашыйк.

* * *

Язын сайрашкан кешеләр
Табын җәя көзендә.
Ипиен кисә тезендә,
Шатлык балкый йөзендә.

* * *

Изгеләр дә, юньсезләр дә
Җир куенында ята.
Гөммәсен үлем тигезли,
Үлемдә буллый хата.

* * *

Яхшылыкны белмәс идек,
Явызлыклар булмаса.
Илне тычкан басар иде,
Мәче тотып тормаса.

* * *

Суда үскән, чүлдә үскән -
Үсемлек дип санала.
Хәсрәттә дә, рәхәттә дә
Гөммә кеше сынала.

* * *

Йомшакның үз сыйфаты бар,
Сыйфаты бар катының.
Тик тиңе юк Галәмдәге
Аң-акыл сыйфатының.

* * *

Йолдызлар - Галәмнәр күрке,
Кара төндә ай кирәк.
Күктәге кояш шикелле
Күңел кояшы кирәк.

* * *

Тозсызны күзсез дә сизә,
Ашның тәме тоз белән.
Тик хәвеф-хәтәрсез яшәү
Аз уйлаган, аз белгән.

* * *

Алтын-көмеш таш булганда,
Алабута аш булыр.
Аш булса да, таш булса да,
Ач нәфескә баш булыр.

* * *

Ачы телле булганнарга
Бал ашарга кушалар.
Ачы белән төзәлгәнне
Бал ашатып бозалар.

* * *

Ашның тәме булсын дисәң,
Татлы тәм-томнар өстә.
Кешене дин тәрбияли,
Күркәм холыклы итә.

* * *

Ябулы казан кайнаса,
Ташуы аның яман.
Биш йөз ел ябулыкта без,
Ташырга җитте заман!

* * *

Аш булса, әшнә табыла,
Табынны ир-ат кора.
Тормыш та бит мал тапканның
Ныклы иңендә тора.

* * *

Сөйдергән дә, көйдергән дә -
Сөйләгән тел, күрер күз.
Сыйларның да иң тәмлесе -
Ихластан елмайган кыз.

* * *

Ачның хәлен туклар белми,
Тукның күңел күзе юк.
Күңел күзе булмаганның
Әйтер җылы сүзе юк.

* * *

Кыш көнендә кар да бирмәс -
Саранның күңеле тар.
Баш иеп саранга барма,
Туганың өенә бар.

* * *

Ашыксаң - ашка пешкәнне
Ашыкканнар да белә.
Ашыгып йөрәген телә,
Әҗәле җитми үлә.

* * *

Кемгә акыл, кемгә нәфес
Хак Тәгаләбез бирә.
Нәфесне акыл җиңгәндә
Шайтан тәмугка керә.

* * *

Кеше гомер буе көтә,
Ак бәхет өмет итә.
Кеше бәхетле булсынга
Бер кәлимә сүз җитә.

* * *

Алтын-көмешләр таш түгел,
Алабута аш түгел.
Алабута аш булганда
Ташка әйләнә күңел.

* * *

Болгар җирен үбә-коча
Үкси татар бабасы:
«Илбасарларга бир, Ходам,
Ике дөнья җәзасы!».

* * *

Тормышта бөтен нәрсә дә
Бер-берләренә бәйле.
Тормыш үзе - дөньякүләм
Сабантуйдагы бәйге.

* * *

Сырхау тән - җанны газаплый,
Эч-башны авырттыра.
Тик күңелне, уй-фикерне,
Карашны савыктыра.

* * *

Хис-тойгылар халәтеннән
Күңел кылы талпына.
Баганадагы чыбык та
Йә бушый, йә тартыла.

* * *

Бер күрүдән бала табу -
Этләрдә, мәчеләрдә.
Гәр чибәргә гашыйк була
Җилбәзәк кешеләр дә.

* * *

Берәү чәчеп тә икмәксез,
Берәү чәчми икмәкле.
Кемнәр укып та акылсыз,
Кем укымый хикмәтле.

* * *

Аты барның камыты юк,
Арбасы да кендексез.
Кем укымый да белемле,
Кем укып та белдексез.

* * *

Берәү гомере буена
Тормыш газабы күрә.
Чөнки ул гомере буе
Башкага газап үрә.

* * *

Бәндә - кол дигән сүз була.
Без кемнең булса колы:
Гыйшык колы, кашык колы...
Гәммәбез - Аллаһ колы.

* * *

Эш кылсаң да, тик йөрсәң дә
Санаулы гомер үтә.
Иңкүлекләргә җыелган
Сулар да сеңеп бетә.

* * *

Тутыккан тимер уала,
Көлгә әйләнә күмер.
Кояш та беркөнне сүнәр...
Тик мәңге калыр гомер?!

* * *

Бөтен нәрсәдә бар хикмәт:
Дөя, энә дә бүләк.
Кунакның акыл нигъмәтен
Зурлый белергә кирәк.

* * *

Изге теләк, яман теләк...
Тели белергә кирәк.
Тели белмәгән тел - илгәк,
Бәла китерер күбрәк.

* * *

Белеме бар - меңне егар,
Дан алыр батыр калып.
Безне тел инкыйразыннан
Тик белем калыр алып.

* * *

Әле бөтерелеп ала,
Әле су кебек ага.
Шаян җилләр буран ясап,
Ак кардан иннек яга.

* * *

Акыллы акылга туймас,
Җүләр - булганын җуймас.
Бер илгә акыллы сыймас,
Бер ил җүләрне җыймас.

* * *

Үзәкнең өзгәләнүе, -
Сагну-сагыштан түгел.
Хыянәтне кичераллмый,
Сыкрана керсез күңел.

* * *

Гөнәрчеләр үз тауарын
Базарга алып килгән.
Илбасарлар сәүдә итә
Ил талаган мал белән.

* * *

Тормышта савыт-сабалар
Шалтырый кемнәрдә дә.
Күкләр күкри, яшен яшьни,
Фолытлар килгәндә дә.

* * *

Мин түгел - Тукай, Такташ та,
Шигъри җанлы Гаташ та.
Тик бәхетле булыр идем,
Фикерем калса ташта.

* * *

Кеше - Галәмнәр тылсымы,
Аллаһның сер сандыгы.
Мәңгегә сер булып калыр
Сандыкта ни барлыгы.

* * *

Әле генә ничек итеп
Зур цәргә дип йөрдем.
Күзләрем ачып-йомганчы
Картлык көзенә кердем.

* * *

Гөлләр цмәгән туфракта
Шайтан таягы цсә.
Шайтан таяклы балалар
Аналар бәгърен кисә.

* * *

Диңгезнең башы - чишмәдән,
Уңыш башы - тәрбия.
Әдәп-әхлакны белгәннәр
Дан-дәрәҗәгә ия.

* * *

Чөйне чөй кагып чыгара,
Кара төнне көн куа.
Күзе туймаган кешене
Кара нәфесе буа.

* * *

Бу дөньяда яшәү өчен,
Эшләсен өчен йөрәк...
Иң кирәкләрнең кирәге -
Кояш, һава, су, икмәк.

* * *

Бар явыз ерткыч ишеләр,
Була хайван ишеләр...
Хөрмәт-мәртәбәгә лаек
Кешелекле кешеләр.

* * *

Беркем дә билгесез түгел...
Гәркемнең исеме бар.
Милләт сатып йөрүчене
Халык каргышы тотар.

* * *

Аллаһ Тәгалә яралтты,
Ул мәңге хуҗаң синең.
Иң кадерле изге затлар -
Газиз әти-әниең.

* * *

Наркоман - заман азгыны,
Спид, яман чиргә хуҗа.
Газап чигеп, үлем көтеп
Япь-яшь гомере уза.

* * *

Күрәчәкнең күзен каплап
Булса да вакытлыча,
Бу дөньяда тормыш бара
Хак Тәгалә кушканча.

* * *

Җыр бәйгесе - концертларда,
Шигърияттә тамаша:
Ир-атлары ташлап киткән
Хатын-кыз ыңгыраша.

* * *

Кояш та бер, Ай да берәү
Батырлар да санаулы.
Ил язмышын үз язмышы
Иткән ирләр мактаулы.

* * *

Динне дә, фәнне дә тигез
Белергә кирәк тирән.
Бишектән ләхеткә кадәр
Укы, гыйлемгә өйрән.

* * *

Хак Тәгалә үз Адәмен
Бер тамчыдан яратты.
Адәмгә башын имәүче
Шайтанга ләгънәт атты.

* * *

Һәр милләтнең үз йөзе бар,
Һәркемнең үз тамгасы.
Татарның юк хәр дәүләте,
Мәстәкыйльлек туграсы.

* * *

Биш йөз ел хурлыкта үтә
Милләтебез гомере.
Һәр татарның маңгаенда
Илбасарның мөһере.

* * *

Дөньяны кризис талый,
Кан-яшьле аның күзе.
Ач ерткычка охшап калган
Кыйбласыз илнең йөзе.

* * *

Илгә бәрәкәт китерсен
Айрат Хәйруллин, Вамин.
Эш-гамәлләре изгелек
Кылуда булсын. Амин.

* * *

Ашыйм дисә, авызы юк,
Киям дисә - гәүдәсе.
Һич кенә дә туя белми
Комсыз кеше нәфесе.

* * *

Җил-бураннар ясап уйный,
Җил урамда шаяра.
Димәк, иләһи Аллаһ та
Уйнап ала берара.

* * *

Хак Тәгалә үз Адәмен
Бер балчыктан бар иткән.
Хак мөэмин-мөселманнарын
Ташламас рәхмәтеннән.

* * *

Кеше - барлык сәнгатьләрнең
Иң югары үрнәге.
Җирдә тормыш булсын өчен
Кешенең бар кирәге.

* * *

Гәрнәрсә кояшка үрли,
Тартыла яктылыкка.
Кеше күңеле дә ия
Кояш кебек аклыкка.

* * *

Кешене данлы иткән дә,
Хур иткән дә - мәхәббәт.
Гөлләрнең дә кайсы җирдә
Үсендә бит хикмәт.

* * *

Җанкисәгем, диеп әйтү -
Җаныңа тиңләү кебек.
Җандашыңа мәхәббәтең
Галәм кебек мәңгелек.

* * *

Шушы өч көнлек дөньяда
Сөенеп, сөелеп кал.
Мәхәббәттә чама белеп,
Кирәк кадәресен ал.

* * *

Без - килеп-китәр кунаклар.
Безнең гомер - ул мизгел.
Җәннәткә тиң Җир-анада
Яшәүнең кадерен бел!

* * *

Бел тормышка ни кирәген,
Ашның нидән пешкәнен.
Бу дөньяда көнкүрешнең
Ни бәягә төшкәнен.

* * *

Язгы боз ястык калынлык
Булса да ышанма син.
Төмле телләргә ышансаң,
Кураллассың рәхәт көн.

* * *

Кеше яшәргә ашыга,
Кабалана бичара.
Ашыккан ашка пешмән,
Ашыкмый яшәп кара.

* * *

Саламга тотынган кеше
Дучар була батарга.
Милли рух кирәк милләтне
Батырмыйча тотарга.

* * *

Дары кебек гөлт итә дә,
Кабынып китә кинәт.
Ялкыны җанны өтә дә,
Сүнә сукыр мәхәббәт.

* * *

Якты кояш тарафына
Бар тереклек үрелер.
Тәүфыйк артыннан еллаеп
Бәхет-шатлыклар йөрер.

* * *

Ил-җиреңә дошман керсә,
Киң күңелең булыр тар.
Бердәмлектә бәрәкәт бар,
Таркауда һәлакәт бар.

* * *

Урыс теле - тур башында,
Башка телләр чуплектә:
Төбәк компоненты дигән
Шовинистик читлектә!

* * *

Кырмыскалар мәйдан тота
Бердәм булганга күрә.
Күмәкләшеп тотынсалар,
Еланны да үтерә.

* * *

Берәү яши ашар өчен,
Берәү ашый яшәр өчен.
Аша, яшә ватан өчен,
Яшәмә - ватар өчен.

* * *

Хәләл акчага алганның, -
Ун бармакка бер балдак.
Хәрам акчага алганның, -
Гүр бармагында балдак.

* * *

Күккә ут-ялкыннар бөркеп,
Җирнең казаны ташый.
Ярсу күңел вулканнары
Җанны, бәгырьне ашый.

* * *

Уйсу җирнең суы кипсә,
Җире ярылып китә.
Милли хис, милли аң бетсә,
Илне һәлакәт көтә.

* * *

Картайган саен телисең
Гомерне озайтырга.
Ләкин... Ләкин кояш бата
Иртән таң аттырырга.

* * *

Саранча яулары үтсә,
Кап-кара буш җир кала.
Җенси азгынлык та илгә
Әхлаки зыян сала.

* * *

Балык баштан чери. Ләкин
Чистарталар койрыктан.
Булдыксыз түрә гаепне
Эзли ярлы халыктан.

* * *

Вөҗдан-намус ерак йөрсә,
Азгынлык якыная.
Затлы әдәп, күркәм гадәт
Тарайганнан тарая.

* * *

Тәртип - тәрбияле булу -
Гүр милләткә хас түгел.
Урлап, талап, хәрам ашап
Яшәве чөнки җиңел.

* * *

Күн итекләрен салдырып,
Кидерттеләр чабата.
Чабаталы шул татарлар
Милләт канында ята.

* * *

Берәүнең күңеле ап-ак.
Берәүнең шомырт кара.
Шомырт кара күңеленнән
Йөзе карала бара.

* * *

Кешене җирдә яшәтә
Хыял, өмет, мәхәббәт.
Күңелдә шул өчлек булса,
Авыр тормыш та рәхәт.

* * *

Тел Киевкә җиткерер, ди,
Теле барның юлы бар.
Киевны да узып киткән
Гаярь идең син, татар!

* * *

Берәүләрдән байлык кала,
Берәүләрдән сүз кала.
Гасырлар бу мирасларның
Хаклысын гына ала.

* * *

Иң данлы сәнгать әсәрен
Хак сөяктән яралткан.
Кызыл балчык белән кушып
Адәм затын тараткан.

* * *

Бу дөньяда бар тереклек
Җирдә нәсел калдыра.
Тик кешенең хокукы бар
Мәңгелектә калырга!

* * *

Кыш көнендә әллә тугангамы,
Мин кышларны шашып яратам.
Өермәле буран котырганда
Ап-ак чәчәк булып мин атам.

* * *

Акыл иясеме, җиһангирмы?..
Борын чәймә, булма тәкәббер.
Кем булсаң да, син тик кеше заты,
Тиңсезлектә Аллаһ бердән-бер.

* * *

Берәүләр аңа табына,
Берәүләр кәсеп итә.
Аллаһның рәхмәт-шәфкате
Барыбызга да җитә.

* * *

Йөз елда да, мең елда да
Туялмам кебек яшәп.
Мәшәкатьле, мәхәббәтле
Бу тормыш бик тә гаҗәп.

* * *

Ишек, тәрәзә бикләнде,
Туганнар да йөрешми.
Сүзеңне тыңласалар да,
Хәсрәтеңне бүлешми.

* * *

Ата-баба гомер иткән җирем,
Кендек каным тамган монда минем.
Оныкларым мәңге сөеп яшәр
Газизләрдән-газиз туган җирем!

* * *

Дүрт яшемдә битемә ат типкән,
Кырык көн башымнан аң киткән.
Бурсыкның эчке маен эретеп,
Эти җәрәхәтемә сөрткән.

* * *

Бәхетне читтән эзләмә,
Бәхетең туган якта.
Ишәккә ияр салганнан
Әверелми ут атка.

* * *

Халык әйтсә, дөрес әйтә:
«Язгы көн ел ашата».
Җир белән тир кушылганнан,
Мәхәббәт чәчәк ата.

* * *

Туй ашлары суынганчы
Син тол калгансың инде.
Азып-тузып йөрүеңнән
Нәселгә оят инде.

* * *

Яман заманда яшибез -
Кешегә акча хуҗа.
Акча эшли алмаган ир
Гарьлектән аяк суза.

* * *

Онытың баласын күрү, -
Бәхетнең иң олысы.
Буыннарга мирас булып,
Күпә җаннар җылысы.

* * *

Мең хата эшләүчеләрнең
Ул гадәтенә керә.
Ә бер хата кылучылар
Гомергә газап күрә.

* * *

Гәркөнне кояш чыкканчы
Намазга ният кылам.
Тәүлек буе Аллаһының
Рәхмәт-шәфкатен тоям.

* * *

Бу дөньяга ерткыч халәтендә
Туганнарның нидә гаебе?
Язмышында язганнарны кылып,
Күрә алар тормыш газабы.

* * *

Ай Кояштан нурлар алып,
Җирне, күкне яктырта.
Иманлы кешенең йөзен
Аллаһ нуры балкыта.

* * *

Гомер үтә кан койсаң да,
Үтә гөл утыртсаң да.
Кан җиргә сеңеп югала,
Гөлдән орлыклар кала.

* * *

Гәркемнең изге бурычы -
Тиешле гомер итү.
Үзеннән соң игелекле
Дәвам калдырып китү.

* * *

Изге кеше дә, явыз да
Бер үк җир куенында...
Тик юллары аерылыр
Ахирәт җыенында.

* * *

Күпме генә уйласаң да,
Галәмнәр урасаң да.
Серләрнең иң яшерене -
Кешеләр арасында.

* * *

Эт тә эшләмәс этлекне
Күз дә йоммый эшлисең.
Баланы чүплеккә ташлап,
Әй, кызый, син нишлисең?

* * *

Берәү әйтә: «Туганмын, - ди -
Үгез йолдызлыгында.
Сөзә торган гадәтем бар,
Үгез холкы канымда».

* * *

Гичкемгә дә, һич кенә дә
Ачу тотып йөрмәдем.
Тормышитагы көйсезлекне
Телем белән көйләдем.

* * *

Бу дөнья төсләрдән тора:
Бар кара төс, бар ак төс.
Ак төс шикелле саф, изге -
Дини фикер, милли хис.

* * *

Катлам-катлам булып китә
Татар зыялылары.
Нечкәрде, юкарып калды
Милли фикер кырлары.

* * *

Бөтен дөнья хәрәкәттә:
Ярала, яши, үлә.
Кешелеккә алмаш булып,
Алтынчы раса килә.

* * *

Офыкларны бер-берсенә бәйләп,
Кара төндә йолдыз атылды.
Яна-яна, очкыннарын чәчеп,
Әйтерсең лә яшен ватылды.

* * *

Матди байлык, рухи байлык...
Аллаһ биргән бәрәкәт.
Бәрәкәтне имансызлый
Нәфес дигән хәшәрәт.

* * *

Тәкъва заттан булыйм дисәң,
Ихрам кирәк киярга.
Әхлаки горурлык белән
«Мин - мөселман!» - диярга.

* * *

Чал тарихка юл сапканда,
Тарырбыз хак-хаклыкка
Пәйгамбәрләр кирәк булган
Азгын, денсез халыкка.

* * *

Гүзәллеге искитәрлек,
Гүштан язып китәрлек.
Йөзендәге нур балкышы
Төнне якты итәрлек.

* * *

Белеме бар меңне егар...
Белемле бул, син, татар!
Дошманнарның, көндәшләрнең
Гөҗүмен кире кайтар!

* * *

Нәселебез - кәҗәмөгез,
Ниятле гомеребез.
Тик бәхет-шатлык китерсен
Изге эш-гамәлебез.

* * *

Җиде саны - хикмәтле сан:
Җирләр, күкләр дә җиде.
Җиде юлның Коръәнлесен
Сайларга язсын иде.

* * *

Бөекләр дә гүргә кереп ята,
Яңәшәдә хәшәрәт тә ята.
Җир-ана икесен дә ярата -
Бер үк гөлләр балкып чәчәк ата.

* * *

Әйтәләр: «Без - татарларга
Яхуд акылы кирәк».
Без дә акыллы булырбыз
Ике меңелны тузсәк.

* * *

Рухи азык булыр фикер
Баш казанында кайный.
Бersen язып, бersen сызып,
Акыл энҗе сүз сайлый.

* * *

Мәхәббәтле бу дөньяның
Гүзәллеген күргән күз.
Бәхетле - шул гүзәллекне
«Яратам», - дип әйткән сүз.

* * *

Дөреслек төрлечә була:
Халыкны гаепләмә.
Тәкәббер «дөрес»легеннән
Ил-җирләр гарипләнә.

* * *

Ашау-эчү, уйнау-көлү -
Тормышның яме, диләр.
Ашый-эчә, уйный-көлә
Гамәлсез-гамьсез юләр.

* * *

Әүвәлдән акыл иясе
Яшәүдән мәгънә эзли.
Мәгънәсе шул: яшәү кирәк
Буыннар җебен өзми.

* * *

Эте-бете акыл сата,
«Мин!» - диргә ярата.
«Колак кисеп, борын яма» -
Дип вәсвәсә тарата.

* * *

Хатын - көндә ашар ипи,
Сөяркә - чәйлек тәм-том.
Иписез син яшәп кара!
...Тәм-том җитә бер йотым...

* * *

Булдыклыдан бар да була,
Кулларыннан эш килә.
Булдыксызлар, һөнәрсезләр
Куык кабарта белә.

* * *

Урысның олы-кечесе
«Россия» дип җирә.
Чирле кеше дә үлемен
Үзе дәшеп китерә.

* * *

Ил халкы чыбык өстендә,
Чиновниклар торбада.
Икесе дә тик утыра
Нефть агып торганда.

* * *

Майлы ризык - тәмле ризык,
Майдан кеше симерә.
Әйтерсең бөтене белән
Эчеңә дуңгыз керә.

* * *

Хокуклары тигезләр дә
Гич була аллыйлар иш.
Кем корабның, кем кармакның
Хуҗасы булуда эш.

* * *

Ике ел имезү фарыз,
Дигән Коръән битендә.
Иланият, рухият тә
Аналарның сөтендә.

* * *

Яман чир, спид сырхавы -
Бозыклык, азгынлыктан.
Кальбләрнең пычраклыгы -
Әдәп-әхлаксызлыктан.

* * *

Хәл-әхвәле гаҗәп була
Гашыйк булса бер кеше.
Сөйгәнен мәсхәрә итә
Гашыйкларның бер ише.

* * *

Халкыбыз гомер буена
Кырларда иген иккән.
Сукалаган, чәчкән урган...
Гомер буе бил бөккән.

* * *

Әйнең рәхәте мич белән,
Ир, хатынның кич белән.
Ир, хатын рәхәтен күрә
Тик ихлас сөя белгән.

* * *

Тимерне кыздыра учак,
Гашыйк кеше бер кочак.
Учак, кочакның ялкынын
Саклый мәхәббәтле чак.

* * *

Камыш судан туя аллмый,
Кеше - татлы ләззәттән.
Гашыйклар ләззәтне ала
Ләззәтле мәхәббәттән.

* * *

Казанның көче учакта,
Мәхәббәтнең - кочакта.
Учак, кочак уты сүнмәс,
Мәхәббәт исән чакта.

* * *

Бөек галим, мәшһүр шагыйрь
Эндәшә гасыр аша:
«Мәй эч, яр сөй яшәгәндә,
Бу дөнья - тик бер рәшә».

* * *

Аек акыл, күркәм холык
Мәселманга хас сыйфат.
Үй-фикере, кылган эше
Изгелектән гыйбарәт.

* * *

Хатын-кыз серле, яшерен,
Оят җирләрен ачты.
Азгыннар өерен күреп,
Шайтаннар куркып качты.

* * *

Ләззәт - иң - татлы хис, тойгы, -
Ул Аллаһ биргән нигъмәт.
Татлы хис, татлы тойгының
Ихлас булуы кыйммәт.

* * *

Иң борынгы кешеләр дә
Илаһ барлыгын белгән.
Йолалар дингә әйләнгән
Заманнар үтү белән.

* * *

Затлы әйбер аунап ятмый,
Затлы әйбер кадерле.
Затлы булу өчен кирәк
Белү үз кадереңне.

* * *

Оят, намусын җуйганнар
Имансыз тормыш кора.
Алар өстендә һәрвакыт
Хәвефле кылыч тора.

* * *

Кеше булып калыйм дисәң, -
Намусыңны саклыйсың.
Исемеңне бер каралтсаң,
Гомер буе аклыйсың.

* * *

Акыл белән яшәгәндә
Тормыш садә, бик гади.
Кешене нәфесе боза,
Көнчелек аны алдый.

* * *

Дөньяның серен белергә
Хикмәти акыл кирәк.
Акылын - ат, нәфесен тик
Арба иткәннәр сирәк.

* * *

Ир - елга, хатын-кыз - инеш,
Икесенең суы көмеш.
Инешле елгада алтын
Балыклар йөзеп йөрмеш.

* * *

Кыр чәчәге горур, көчле,
Ой гөле нәзакәтле.
Гөл, чәчәкләр кебек күркәм,
Булсакчы бәрәкәтле.

* * *

Коры елга - сусыз елга,
Каз, үрдәкләр коенмый.
Күңеле буш кешеләргә
Көчекләр дә сыенмый.

* * *

«Хаксызның күзе яшьле», - дип,
Бик дөрес әйткән халык.
Елап акланмак булганның
Сүзендә юктыр хаклык.

* * *

Юл-суккакка үлән үсми -
Өзелми аннан кеше.
Нияте изге булганның
Җир-күкле булыр эше.

* * *

Сынала сугыш кырында,
Сынала юл барганда.
Бигрәк тә кеше сынала
Әҗәтен кайтарганда.

* * *

Гәр күҗәйдән чеби чыкмый,
Кысыр була калганы.
Кешенең дә кол булганы -
Кай гадәтләр корбаны.

* * *

Кешенең гомере буена
Күзләре гашыйк була.
Тик бер генә мәхәббәтне
Кешегә биргән Алла.

* * *

Сагыш - җан, күңел газабы,
Сагыну - ачы ләззәт.
Кемгә мәхәббәт тә зәхмәт,
Кемгә ул - затлы хикмәт.

* * *

Эй, татарым, үз-үзеңне
Танытырга тап әмәл.
Олуг Мөхәммәт шикелле
Кыл изге милли гамәл.

* * *

Кибән кадәр ана дуңгыз,
Исеме аның хәрәм.
Хәрәмләшеп харап була
Татарым берәм-берәм.

* * *

Син кемнәргә охшап калдың,
Көзгедән бер карале?!
И татарым, үзеңә кайт,
Үзеңне танып әле!

* * *

Бит борын-борын заманнан
Татар үз-үзен ашый.
Бел! Кайарман бер ир-егет
Яманнан яхшы ясый.

* * *

Чишмәләрнең сихри суын эчкән
Болыннарда гөлләр балкышы.
Гаваларда талгын дулкынланган
Иген кырларының алкышы.

* * *

Кырыс табигатьнең кочагында
Кыр чәчәге үсә яланда.
Күркәм калыр... Кояш, ай нурыннан,
Җир-анадан куәт алганда.

* * *

Бер аланда карт мәһабәт имән,
Әйләнәдә шаулый зур урман.
Тамырлары тоташ берегешкән
Яшь имәннәр аны ураган.

* * *

Кулыма каләм алуым
Бик соңга калып булды.
Гомер буе күз алдымда
Халкым язмышы торды.

Казан, 2005-2009 еллар.

Искәрмәләр өчен

Искәрмәләр өчен

Искәрмәләр өчен

Рәис Сафин

АКЫЛГА МӘДХИЯ

(Робагыйлар)

Редактор *Рашат Низами*
Рәссам *Рушан Шәмсетдинов*
Компьютерда версткалаучы
һәм техник редактор *Л.В. Мәгыйзова*

Сдано в набор 7.04.2010. Подписано к печати 20.05.2010.
Формат 60x84 1/16. Бумага офсетная.
Гарнитура «Арбат». Печать ризографическая.
Усл. печ. л. 13,5. Тираж 500 экз. Заказ К-142.

Министерство образования и науки РТ
Редакционно-издательский центр.
420111, Казань, Дзержинского, 3. Тел.: 292-24-76.
Отпечатано на множительном участке центра.

